Рүзәл Мөхәммәтшин

# Каралама

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М98

**Мөхәммәтшин, Р.Ф.**

Каралама : шигырьләр / Рүзәл Мөхәммәтшин ; кереш сүз авт. Г.Морат. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 127 б.
ISBN 978-5-298-01856-2

Яшь шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшинның беренче китабына аның лирик-фәлсәфи шигырьләре туплап бирелде.
УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
ISBN 978-5-298-01856-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Мөхәммәтшин Р.Ф., 2010

## НОКРАТ УРГЫП АГА...

Безнең якларда иң кызу ага торган елга Нократ бугай. Әмма, ни гаҗәп, элгәрләребез аның исемен җырларга кушып җырламаган диярлек. Хикмәт нәрсәдә? Әллә соң алар елганың дуамал холкын өнәп бетермәгәнме? Әллә Нократ кәлимәсе үзе үк көйгә салыр өчен җайсызрак, ятышсызрак булып тоелганмы? Әллә инде тагын да җитдирәк берәр сәбәбе табылганмы?

Ә менә 20 яшьлек шагыйрь Рүзәл Мөхәммәтшин, җанына тынгы эзләп, Чулман-Иделләр кочагына барып сыенырга ашкынып йөгергән гаярь елгага: «Акрынрак ак, Нократ», – дип эндәшә.

*Алай ашыктырып кума әле,*
*Зинһар өчен, бераз көттерим! –*
*Җырым кала, җырланмаган җырым!..*
*Шуны гына җырлап бетерим...*

Бер караганда, Рүзәлдәй ять-яшь егеткә болай сөйләнү ничектер килешеп тә бетмидер кебек. Ләкин, нишләмәк кирәк, ул Вакыт-дәрья агышын күрү, ишетү куәсенә ия шагыйрь дә шул әле. Ә шагыйрьгә, кем әйтмешли, хан башмагы да, дәрвиш чапаны да бердәй килешеп тора.

Нократ буенда туып үскәнгәдер, нократлык чалымнары Рүзәлнең үз холык-фигыльләндә дә ачык шәйләнә. Ашкынулы сабырлык та, ярсу олпатлык та бар бу егетнең калебендә. Ә чын шигырь дигәннәре әнә шундый калебтә генә ярала да торгандыр инде.

*Мин күптән хыялсыз яшим – җанымда минем богау,*
*Әйт, әнкәй, гаепмени ул башкалар кебек булмау?..*
*Хәзер барсы үзгәрде шул: кем хиссез, шуңа улай.*
*Ә без инде һәммәбез дә акылдан яздык бугай...*

Дөресен генә әйткәндә, мондый шигъри юлларны әле яңарак кына балигълык яшеннән чыккан үсмер егет язганына хәтта ышанасы да килми. Бер үк вакытта сискәндерә дә, сокландыра да Рүзәлнең шигырьләре. Ә иң мөһиме, аларда милли гамь бар. Шуңадыр шагыйрь иҗатында үз яшеннән дә, яшьтәшләреннән дә бераз өлкәнрәк күренә кебек.

*Шаһгали күкләрне тудырган бу халык*
*Иелде мәңгегә, толерант кол калып...*

Моңарчы «толерант кол» дигән гыйбарәне ишеткән юк иде әле. Чынлыкта да шулай бит: толерантлыкны нишләптер гел коллардан гына таләп итәләр. Әгәр инде толерант икәнсең, синең үз хокукларыңны дауларга да хакың юк. Сиңа хәтта үз телеңдә уку да, укыну да тыела. Кешенең кадере булмаган җирдә мөкатдәс сүзләр дә, кыйммәтен югалтып, бөтенләй кире мәгънә аңлата башлый, күрәсең.

Бу җәһәттән шагыйрьнең «Эльдорадо» дигән шигыре аерата гыйбрәтле:

*Бу җирдә күк күптән каралган,*
*Бу җиргә төшми ай яктысы.*
*Бу җирләр уратып алынган,*
*Бу җирләр – дөньяның яртысы...*

* * *
*...Монда йә яшисе кол булып,*
*Монда кол булып йә үләсе...*

* * *
*...Монда һәркем өскә үрмәли,*
*Тәгәрәп төшәргә бергәләп...*

Белүебезчә, Эльдорадо үзе әкияти байлыклар иле дигәнне аңлата. Илбасарлар исә тарихлар дәвамында әнә шул серле, могҗизаи илне эзләп табып, яулап алу турында хыялланган. Билгеле, һәр илбасарның үз Эльдорадосы булган. Ә тора-бара ул ил халкы-ние белән тоташ хәрабәгә әйләнгән. Хәер, «дөньяның яртысы» әле хәзер дә, могҗизаи байлык өстендә утырган килеш тә, хәрабә хәлендәрәк көн итеп ята түгелме соң? Шигырьдәге киная дә шуңа ишарәле түгелме?

Әмма бер нәрсә ап-ачык: шагыйрь үзе мондый шартлар белән беркайчан да килешеп яши алмыйдыр. Шул халәте аны берөзлексез тынгысызлап, борчып, бимазалап торадыр. Шул халәте аны кулына кабат каләм алырга мәҗбүр итәдер.

Ахыр чиктә шагыйрьлек үзе дә ачына-ачыргалана белүдән башланмый микән әле? Ихтимал, шулайдыр, юкса әнә яшь-яшь шагыйрь егетебез дә тиктомалдан: «Мин үземә урын таба алмыйм», – дип өзгәләнмәс, бәргәләнмәс иде.

Ә Рүзәлне тынгысызлык тойгысы беркайчан да ташламас, иншалла. Ни әйтсәң дә, үзебезнең Нократ егете ич ул. Ә Нократның холкын үзегез беләсез...

*Газинур Морат*

## I бүлек

***Үткәннәрне эзләп табар өчен,***
***Бу юллардан мин аз үтмәдем...***

### КАРАЛАМА

Кул астымда минем – каралама...
Иренмәсәң, карап бак, туган:
Ике дистә еллык гомеремнән
Җөмлә-җөмлә сызып атылган.

Теткәләнеп беткән каралама...
Кыюлыгым җыям да бераз,
Хаталарны төзәтмәкче булам –
Чуарлана гына ак кәгазь.

Һәр юлында өзек-өзек мизгел
Тормышымнан минем, үткәннән.
Язам, сызып атам... Чүп чиләге
Көннәр белән тулы күптәннән...

Күз алдымда минем – каралама...
Горур да ул, серле, ямьле дә...
...Ике дистә еллык гомеремнең
Каралама чагы әлегә...

### ТАҢ ВАКЫТЫ

Төн караңгы, тик таң атсын әле,
Һәм көн сабый булып туачак.
Һәр иртәне кичләр куган кебек,
Бу төнне дә иртә куачак.
Кичәге ут су буенда янмый,
Күккә очкан чаткы да сүнгән.
Бирер әйберем юк, Раббым, сиңа,
Ә сорарга нидер күпсенәм...

Җиләс һава... Рәхәт һәм сагышлы!..
Яннан гына чишмә йөгерә...
Борыласы түгел иде икән,
Бер юл буйлап киткәч кирегә.

Зәңгәр томан әкрен генә шуа
Тын йоклаган кырлар өстеннән.
Бирер әйберем юк, Раббым, сиңа,
Ә сорарга нидер күпсенәм...

Дөнья тарттым, аның белән бергә
Тартканмын бит еллар җепләрен.
Үткәннәрне эзләп табар өчен,
Бу юллардан мин аз үтмәдем...

Таң вакыты... Җиһан йоклый әле,
Бер мин генә никтер көрсенәм...
Бирер әйберем юк, Раббым, сиңа,
Ә сорарга нидер күпсенәм...

Җиләс һава... Рәхәт һәм сагышлы!..
Яннан гына чишмә йөгерә...
Борыласы түгел иде икән,
Бер юл буйлап киткәч кирегә.

Офык кызгылт-сары төскә кергән
Кара-кара булган төсеннән.
Бирер әйберем – җан, Раббым, сиңа,
Тик бирергә аны... күпсенәм...

* * *

Ай сыенды болыт артларына,
Утлар сүнде.
Тормыш – йокыда...

*Х.Туфан, 1956*

Ял итәргә вакыт барысыннан,
Ардырды бу дөнья дигәне,
Эх, аңласаң иде бу җанының
Нәрсә генә эзләп йөргәнен.
Кышкы урам.
Буран гына һаман
Тәрәзәгә ап-ак кар сибә,
Һәм күмелеп киткән кара туфрак
Йокы аша авыр көрсенә.
Авыл тып-тын,
Авыл йоклый инде.
Берән-сәрән кайсыдыр гына
Нидер сөйләп
Тамак кырып куя,
Нидер сөйли һаман һәм...
Тына...
Ак морҗадан төтен күтәрелә...
Ак морҗадан җылы пар менеп,
Әле генә туктап калган берәү
Кабат узып китә сүгенеп...

Һәм...

Төн җиткән.
Кара, караңгы төн.
Нәрсәдәндер качкан шикелле,
Ак ай гына болыт арасына
Яшеренә.

Әйе, төн килде...
Әйе, тагын бер көн үтте...
Әйе!..
Тагын бер көн ертып алынды.

Тагын ашыктырды барсын вакыт,
Һәм яңадан соңга калынды.
Тәрәзәдән тыш яктысы төшә,
Тәрәзәгә ак кар коела.
Бик ерактан бер билгесез кызый
Яулык болгый кебек тоела.
Ә бүлмәдә – җылы.
Почмактагы
Сәгать кабат җитте яртыга,
Ә еракта – урман...
Караңгылык,
Билгесезлек аның артында...

Әйтерсең лә рәшә вәгъдә итә...
Әйтерсең лә рәшә үтелгән...
Тәрәздән җил кереп үбеп ала
Агарынган маңгай битемнән...

Тик...

Төн җиткән.
Һәм караңгы күптән.
Нәрсәнедер эзли шикелле.
Ак ай гына болытларны куып
Аска карый.

Әйе, төн килде...

## ӘЛХӘМ

Бар догалар кире кайтты менә,
Бар әйтәсе менә әйтелгән.
Соңга калганмын бит, бик нык соңга!..
Кирәгеннән артык көтелгән...

Фәрештәләр кире какмый күптән.
Фәрештәләр белә барысын –
Бүгенгедә булган хаталарны
Тик иртәгә миңа аңлыйсы...

Онытылган сүрә... Ябык Коръән.
Ә һәммәсе башка иде бит!
Борыласы килми артка, ләкин
Алдымда да берни күренми.

Мин Аллаһны ташлап, гомеремне
Өзелмәгән кылга тапшырам...
Мин онытам Аны, тик язмышым
Кабат илтә Аның каршына...

## КАЗАН

Аллалар онытты яшьнәгән халыкны.
Шартлаган стенадан мәетләр калыкты.
Һәм йотты томанда шәфәкъны тын Идел.
Ахыргы каһарман кем иде? Син идең!..
Өзелде мәңгегә яңгыраган хөр азан,
Калыккан туң кояш эреде бераздан –

Казан!..

Батырып ал канга кыйналган милләтне,
Яңалар яңадан һәммәсен өйрәтте.
Күтәрде өскәрәк күгәргән тәресен,
Син күрдең! Күрмәгән гомумән күрмәсен...
Әрнетә йөрәкне тотмаган уразаң,
Туктады көн язда, башланса да яздан,
И Казан!..

Шаһгали күкләрне тудырган бу халык
Иелде мәңгегә, толерант кол калып,
Һәм җанны череткән канлы хач урынына,
Бүген үз канын һәркем үзе суыра... –
Ханбикәң күк горур манараң бераздан
Ишелер микәнни өстеңә, чал Казан?
Әйт, Казан?!

## АКТА КАП-КАРА ЯЗУЛАР

Сибелгән мизгелләр аша саналган адым атлап,
Хыялга вәгъдә бирәбез, иманны кабат ятлап.
Барсы зыян түгелмени? Әлбәттә, файда барсы!..
Без язмышка каршы түгел,
язмышлар безгә каршы.

Акта кап-кара язулар – кәгазь түзә барсына.
Тик, имән дә ауган кебек, инә дә чатнап сына...
Болар барсы юкка чыгар, хәтта булмаган кебек,
Тик кәгазьдә түгел – җанда,
Канда калачак өмет!
Мәңге калачак өмет!..

Бер җөмлә һәм сызылган сүз, хәрефләрдә –
кара тап.
Күзләрне йомып үтәбез хаклык битләрен таптап.
Булганы тиз онытыла, булмаганы – хәтердә.
...Безнең күзләр азатлыкны рәшәткә аша күрә.

Акта кап-кара язулар...
Акта кап-кара язулар...
Акта кап-кара язулар...

## МИНЕМ ДУСЛАР

Мин бүлмәгә кердем – бүлмәм тып-тын.
Бүлмәм буп-буш, мин – ялгызым, тартам утын –
Ут кабына, һәм алдымда:
Ауган шешә, калдык консерв, ватык төпчек.
Мин бик күпне бирдем монда яшәр өчен.

Сигаретның ачы исе ютәлләтә.
Кояш ава тау артына – бу көн үтә.
Һәм иртәгә дә көн үтәр,
Һәм таң атар, һәм төн җитәр, йолдыз сүнәр.
Дуслар кайтыр һәм түшәктә мине күрер...

Минем дуслар бу тормышны үтә ярып,
Ә мин тып-тын бу бүлмәдә ятам арып.
Минем дуслар бу тормыштан нидер көтә.

Ләкин көннәр бу бүлмәдә,
бу тормышта эзсез үтә...

...Бүлмә буп-буш иде, хәзер инде
Минем янга дуслар – яңа дуслар килде.
Мин аларны белми идем, алар – мине,
кемлегемне.
Таныштырды
Безне язмыш һәм һәммәсен кире борды.

Сәгать суга, вакыт җебен сүтә-сүтә...
Кояш ава тау артына – бу көн үтә.
Һәм иртәгә дә көн үтәр,
Ә әлегә –
Ауган шешә, калдык консерв, ватык төпчек...
Мин бик күпне бирдем янә дуслар өчен.

*** * ***

Син беләсең,
Мин
Үзгәрдем күптән.
Нидер булды, нидер эшләдем...
Әмма сүкмә: «Аны оныттың!» – дип,
Мин ялварам Аңа кичләрен...
Ачуланма – читтә калды Коръән,
Һәм аңлагач, авыр бигрәк тә.
Тик яшәргә мине күптән инде
Гел икенче максат өйрәтә...

## КЕЧЕ ЯКТА

Дүрт тар стена, алар арасында
Мин тын гына таңны көтәмен.
Тамчы тама краннан, тик мин сизәм
Йөрәгемнең ешрак типкәнен.

Газ гөжелди, ал шәм электр утын
Алыштырып яна бүлмәдә.
Йөрәк астын нидер кыймылдата,
Ниндидер хис калган тирәндә.

Бетон идән салкын, һәм салкынын
Гәүдә тоймый күптән, тик күңел
Тоя аны. Уянырга кирәк!
Әмма болар барсы төш түгел...

Ә анда, тәрәзә артында,
Эзлидер котырып җил куыш.
Һәм ега юлчыны аяктан,
Һәм көтә юлчыны борылыш.
Ә анда, тәрәзә артында –
Тормыш...

## ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Нәрсә булды, ник үзгәрде барсы?..
Кая киттең әле? Туктап тор!
...Мин тормышны аңлый

алмыйм һаман,
Ә ул мине аңлый алмыйдыр...

Бәргәләнә йөрәк, күкрәгемне
Ярып чыгар иде, булдырса...
– Энем, тукта, рәхмәт әйтер идем,
Бер сигарет кына калдырсаң...

– Тартмыйм, абзый, – дим дә ары китәм.
Нинди дөнья соң бу? Һәммәсен,
Тамырыннан умырып алып кына,
Таптый-таптый җиргә күмәсе...

Барысы да туйдырды, барсы да!
Кич җиттеме – кабат моңсулык...
Киң урамнан эшсез күк «аксаклыйм»,
Җылы ни дә миңа, ни суык...

Берни инде юатмый күңелемне,
Берни инде чиртми кылларга...
Тирән итеп бер сулыйсы иде,
Һава җитми тирән суларга!..

Нәрсә булды, нәрсә үзгәрде соң?
Шул ук тормыш, шул ук барсы да, –
Тик моңарчы кайчак ярсу иде,
Хәзер түзеп булмый ярсуга...

Хәлсезләнгән йөрәк. Үзем боздым
Хәтта юкка гына да борчып.
– Абый, – диде берсе, – зинһар өчен,
Бер сигарет кына калдырчы...
– Тартмыйм, энем...
Борын төбең юеш,
Маңка тәре, бирмим! Тартмый тор!..
...Мин тормышны аңлый алмыйм һаман,
Ә ул мине аңлый алмыйдыр...

## БАШКАЛА

Караңгы башкала кабыза утларын.
Күләгә хәтерли якында мин барын...
Мөгезен сындырып, узыша трамвайлар.
Ашыга гасырлар, мизгелләр һәм айлар...
Югала эсселек салкын төн өстендә.
Һәм юеш шырпылар кабына да сүнә...
Бу төн беркемне дә беркая чыгармый,
Йөрәктә моң гына тынмый һәм тукталмый...
Ишелгән чатырлар һәм кара тар оя...
Монда бары өмет, монда бары хыял.
Ләкин бу хыялга ярарга да кирәк –
Ул синнән югары, ул синнән өстенрәк...

Узыша, чабыша, ашыгалар алар,
Яныңнан үтәләр, каршыга баралар.
– Хәлләр ничек, кардәш?..
– Начар түгел, ипләп…

Гафу ит мине, кем… Мине кемдер көтә…
Йөгерә бар шәһәр… Һәр секунд кадерле!
Почмакта чал карчык кына җон җегерли…
Аннан кабат яза – тормышны чистарта… –
Чүп арткан вакытта – чистасы да арта.
Таң ата, ә аннан яңа көн башлана,
Тәмамланмаганы шунда ук ташлана.
Чүплеккә ишелә хәтердә булганы,
Һәм шундук онтыла – кирәге юк аның…
Бер күзне йомып без алгарак карыйбыз.
– Син кая барасың?
– Еракка…
– Ярый, уз...
Чирәмдә күлдәвек, ә анда кояшның
Суынган нурлары яшерә карашын.
Монда барсы башка, монда барсы үзгә...
Һәм уйлап карасаң, урын юк күк безгә.
Тик сулыйбыз без шул машина һавасын, –
Кем белә тормышның кай якка агасын?..
Һәм калабыз монда, һәм киләбез кабат.
Мин сөярмен сине, ләкин син дә ярат,
Мине, ак башкалам, чит итмә! Аннары...
Бар әйткән сүземне мин кире аламын.

**ҖАН САГЫШЫ**

Дустым, төтәт әле тәмәкеңне,
Бер буылыйк сасы төтенгә.
Берни әйтмим, зинһар, сорама да,
Берни әйтмим, зинһар, үтенмә...

Сару кайный...
Бер «уф!» дисәм генә,
Узып китмәс инде һәммәсе...
Күргәннәрне күреп үттек бераз,
Күрмәгәнне калды күрәсе...

Нәрсә эшләп инде ялгышмаска
Һәм ялгышмас өчен нишләргә?..
Бар читлекне бәреп ватып кына
Юл табасы иде хисләргә...

Бу сәгатьләр... Бу туктамас вакыт,
Кая чаба икән, ни куа?
...Нәрсә көтәр китүемә мине,
Нәрсә көтмәс инде кайтуга...

**КӨЗГЕ МОҢ**

Ак каенның яфраклары очып
Әкрен генә куна иңемә.
Димәк, кабат сары көзләр җиткән,
Һәм кояш юк кабат күгемдә…

Кичәге көн инде үттемени –
Ник алайса бу көн җитмәде?
Кабат көзләр килде, ә күңелдә…
Ә күңелем моны көтмәде.

Нинди сагыш!.. Болыт арасыннан

Ник бер нуры җанны җылытсын!..
Мин барысын оныта алмамындыр,
Әмма барсы мине онытсын…

Күңелдә – көз... һәм шул ук көз атлый
Мин тын атлап үткән урамнан…
Исән калган чәчәк сыкрап сула
Иртән җиргә төшкән кыраудан...

Җир кичерә барсын, йә Ходаем,
Син дә кичер туфрак улларын!
Син каргама безне: «Тормышлары
Тормыш түгел, – диеп, – боларның...»

Без онытсак каушап иман сүзен
Һәм онытсак Сиңа барасын,
Барсы сүнәр, әмма өмет булып,
Зинһар өчен, якты ут янсын…

Тормыш безнең шикәр түгел лә шул,
Без тоябыз моны һәр көзен.
Тик ярасын елап төзәтә көз
Һәм кичерә безне берүзе…
Без яшибез Синең тарафыңнан
Яратылган башка меңнәр күк.
Син беләсең, мин бит әзер идем
Калдырырга барсын бүген үк…

Тик үләсем килми икән минем!
Һәм Син кисмә минем гомремне…
Ә мин Сиңа соңрак, вакыт җиткәч,
Үз җанымны үзем бирермен.

Тик онытсам, йә күрмәсәм Сине,
Һәм онытсам Хөкем буласын,
Барсы сүнәр, әмма өмет булып,
Зинһар өчен, якты ут калсын...

**ЯР ЧАЛЛЫ**

Яр Чаллы, син горур, син тыйнак, ягымлы.
Күзәтәсең ярдан тормышлар агымын...

Ләкин мин
нигәдер
танымыймын сине.
Танымыйм йортларың,
Чулманны танымыйм...
Сиңа нидер булган.
Чал кунган.
Соң инде...
Кил, ташлы йөзеңә бер генә кагылыйм...

Яр Чаллы, кызганыч, син миннән уңмадың!..
Һәм эзләп югалган машина эзләрең,
Әллә мин күптәннән бу җирдә булмадым,
Әллә син бу җирдә артык тиз үзгәрдең...

Син июль эчендә – берүзең.
Мин синдә
Нәрсәдер тапканда – нәрсәдер югалттым...

Мин яттым бер кичне, уянмам башка дип,
Тик мине син, Чаллы, бик иртә уяттың!
Син мине июньнән июльгә озаттың...
Һәм барам июльдән – дөнья киң, дөнья зур, –
Исемсез проспектның урап һәрбер чатын,
Кайсыдыр тарафка, кыйблага каядыр...

## МИЛЛӘТ ЮК УЛ, ДИЛӘР

– Милләт юк ул, – диләр, – яшәде яшәсен.
Хәзер бу халыкка чит телдә дәшәсе.
Кояшын югалтып караңгы сарайда,
Ул улый бүре күк, табынып ак айга.
Һәм соңгы сулышта, иманын югалтып,
Төкереп барсына, ул таптый үз антын.

– Милләт юк ул, – диләр, әрнетеп ярамны.
Күзгә яшь тыгыла, еламыйм, ярамый.
Берни дә үтмәгән! Һәм азан тавышы
Барсына чик түгел, барсының тик башы!
Мин атмыйм чәчәкләр кабере ташына,
Чөнки мин ышанам, ышанам халкыма.

– Милләт юк ул, – диләр, – яшәсен яшәде.
Авызны яптылар, ләкин кем дәшмәде?
– Ә җәнлек ул, – диләр, – үлеме алдыннан
Кычкыра да дулап, яңадан кабына.
Ләкин кем җәнлек соң? Мин протест белдерәм!
Онтылган хакымны кайтарам бүгеннән…

– Милләт юк ул, – диләр, – ләкин кем исбатлар?
Ник иртә күмәсез? Әле мин бит татар!
Кояшны югалтып, караңгы сарайда
Уламыйм бүре күк, табынсам да айга.
Һәм үзен тапмаган милләтем өчен дә
Мин саклыйм антымны йодрыгым эчендә...

## МИН – ЯРКАНАТ

Ник кыздыра мине кояш,
Ник мин әле һаман юаш?
Ник мин аңа әле һаман җавап бирмим?
Күзләремне ул томалый,
Миңа нурлар бит ярамый!
Мин бары тик җиргә шәүлә атып йөрим.

Мин, кара төн җитте исә,
Очып, болытларны кисәм
Һәм ашкынам күккә – йолдызларга кабат.
Тик күренде икән ал таң,
Мин йортыма кереп ятам,
Иртән кабат торыр өчен, мин – ярканат.

Бу җирләрдән мин ялгызым
Төнлә очып бик күп уздым.
Һәм бик күпне үзем күрдем айлы кичен.
Мине кайда да көтмиләр,
Беркайда да үз итмиләр,
Нинди каргыш йөртәмен мин һәм ни өчен?

Кемдер аулый, кемдер ята,
Тик тынгы юк ярканатка.
Тормыш шундый – төрле язмыш, төрле өлеш.
Кояш чыга атып утлар,
Минем йөрәк бермәл туктар.
Булмам мин, әмма хәзер – качарга тиеш.

## БАШКАЛА. АК МӘЧЕТ

Караңгы вагонда томанлы уй-хисләр.
Еракта-еракта салкын ай нурлары.
Бармаклар аралаш яктылык күренсә,
Яшисе иде дә, тик яшәп булмады.
Чит йөзләр, үзләрен бүреләр диярсең, –
Күзләре сусаган тормышка һәм канга.
Тик чынга ашарлык хыяллар иярсез,
Билгесез тизлектә ашыга Казанга.
Сигарет төтене күз алдын томалый.
Авыру җан гына битараф барсына.
Кабат баш авырта – нишлисең, булгалый,
Ахыргы тукталыш Ак Мәчет каршында…

Багана яктысы аера икегә
Караңгы шәһәрнең чит һәм ят якларын.
…Син мине сакладың барсыннан, тик нигә
Мин каршы чыкканда башканы якладың?
Башкала. Ак Мәчет. Җил җанны өшетә.
Көчекләр улаша чүплекне актарып.
Мөәзин биектән дөньяны күзәтә
Һәм укый азанын, бугазын куптарып.
Ә аста кыргыйлар, җыелган хәердән
Бер өлеш чыгарып, махмырын дәвалый.
Һәм шулай башлана монда һәрбер иртә:
– Энем, баш авырта.
– Ну, абый, булгалый...

Барысы яхшырыр, барысы үзгәрер
Диеп, без никадәр юаттык күңелне.
Энем, ул көннәрне син күрерсең әле!
Менә без генә нык ялгыштык түгелме?
Ни өчен боларның һәммәсе дә безгә –
Үзеңне оныту бик кирәк идеме?..
Барысын төбеннән җимердек тиз генә,
Һәм кулга яңадан богаулар киелде...
Аллаһ ул бардыр бит, инде бу шашуга
Ул күрер иде бит – барсын җен куалый...
Аракы кибете Ак Мәчет каршында:
– Абый, баш авырта.
– Ну, энем, булгалый...

Ай, юкка ышандык, ай, юкка һәммәсе,
Утырып чәчләрне йолкыйсы калды тик.
Югалган ден кире кайтмыйдыр, күрәсең,
Ә үткән көннәргә кайтасы иде бит!
Сәгать һаман кичке тугызны күрсәтә,
Ә офык кызарган, инде ал таң ата.
Мөәзин биектән үк безне күзәтә
Һәм моның барсына фатиха тарата.

Ай, юкка ышандык, ай, юкка барсы да...
Җитмәсә, йөрәктә һаман шик югалмый.
Мин япа-ялгызым Ак Мәчет каршында,
Бары баш авырта – булгалый, булгалый...

* * *

Дөнья ап-ак.
Әйтмәгәннең
Барысы – хак.
Юкка нахак...
Ә юл – ерак...
Ак кар...
Алга карап,
Йодрык янап
Барасы бар...

Ә күзләрдә –
Җан ачысы...
Биткә төшә дә юк була
Кечкенә яшь тамчысы...
Ә юл ерак...

Учта бары
Тормыш юлы аунап ята.
Һәм ак карны
Кулга алып
Нык кысасы килә...
Буранлата...
Агачларда – ак бәс,
Тәрәзәгә
Рәсем ясый гыйнвар.
Тәрәзәдә дә
Нindидер моң-сагыш.
Таныш, таныш
Һәммәсе дә.
Һәм яше дә
Катып кала биттә.

Ә юл ерак...

Шактый үтелде,
Тик шактый
Үтәсе бар...

Һәм бары тик
Шушы ак кар
Ниндидер бер өмет өсти кебек,
Арындырып җаннан пычрак-чүбен,
Тынычлану бирә.
Ә кем белә,
Бәлки,
Барысы да
Рәшә генә...
Юк.
Яшә генә
Бары,
Яшә генә!..
Сабырсыз җил.
Сызганган җиң.
Сөртелгән яшь.

Миңа да дәш
Кузгалганда,
Яме, иптәш?
Әле
Җанга тыныч бераз,
Моңсу түгел.
Озакламый килер
Кабат
    ямьле,
        алсу таңлы
            яз.
Күк агылыр болытлардан
Һәм яңадан
Соңга калган,
Онытылган
Хисләр
Үсәр.
Шиксез ансы.
Һәм күрерләр барсы –

Бу кыш үткән,
Сагыш беткән,
Сагынып-сагынып көткән
Көннәр җиткән...

Хак –
Дөнья әле ап-ак.

Һәм әлеге әйткән барысына
Ара ерак.

Бары ак кар...

Алга карап,
Йодрык янап,
Җанны ямап
    түзәсе бар...

**МИН – ТАССР УЛЫ**

Май таңында туганмын мин,
Ни кичергән дөнья – белмим.
Сипкәндер җил елга комын
Киметергә тавышымны,
Бәрелешкәч чүкеч-урак,
Шәфәкъны ун меңгә турап...
Ул заманнан мин соң буын,
Мин – ТАССР улы.

Мин байракның алын күрдем.
Мин байракка җанны бирдем.
Мин гауганы хәтерләмим,
Сорама – мин берни белмим.
Әмма күрәм, күңел тоя:
Күз алдымда башка дөнья,
Һәм хәтерлим – мин соң буын,
Мин – ТАССР улы.

Мин туганда, бу ил мине
Назламады һәм сөймәде.
Йоклатмады хөр гимн кичен –
Мин һәммәсен ялгыз кичтем!

Совет иле – минем анам,
Башым иям, горурланам.
Тик ул чордан мин соң буын,
Мин – ТАССР улы.

**ЯРЫМ АЙ**

Минем өмет. Минем сагыш. Каргыш.
Югалтылган хакның бер ташы.
Җилдә уйнап өзгәләнгән байрак.
Һәм кемнеңдер үчле карашы.
Меңнәр-меңнәр башын күтәрәчәк.
Тик әлегә бары кош кебек,
Күкрәгемне ертып чыгар өчен,
Йөрәк кенә тибә интегеп.

Безнең күктә ак ярым ай яна,
Татар буылганда төтендә,
Ул – соң өмет безнең бу төндә...

Хәтере юк милләт киләчәксез.
Әмма хәтер белән көз килде.
Меңләп-меңләп башын күтәргәннәр
Меңләп-меңләп-меңләп баш иде!
Һәм югалды кыйбла, ятим милләт
Мәңгегә ваз кичте барсыннан.
Йөрәк кенә тибә хакыйкатьнең
Югалтылган ташы астыннан.

Безнең күктә ак ярым ай яна,
Татар буылганда төтендә,
Ул – соң өмет безнең бу төндә...

**ХАЛКЫМНЫҢ КӨЙЛӘРЕ**

Мин күрәм: урамда эретә яз карны,
Һәм тамчы тамыза кыегы өйләрнең.
Инде мин булмасам, кем җырлар аларны –
Онтылган халкымның үлемсез көйләрен?

Монда барсы башка, ләкин моң һаман шул,
Һәм аша тормышка һәр эзе юрауның.
Җил уйный кылларда, ләкин ни уйный ул? –
Онтылган халкымның үлемсез җырларын...

Үткәнен, бүгенен, киләчәк көннәрен
Ул тыңламаса, мин кемнәргә сөйләрмен?
Һәм җырлармын кемгә басып җан шаукымын
Онтылган халкымның үлемсез көйләрен?

*** * ***

Салкын җир – туң туфрак.
Тик шәһәр әкренләп
Кыш буе өшеткән карыннан арына.
Сәгатьләр ашыга һәм үтә көн-көнләп,
Куалап-куалап һәммәсен, барын да...

Ә ачык тәрәздән җил эчкә йөгерә,

Тормышым юлының битләрен кубарып,
Почмактан почмакка көннәрне җыеп,
Куалап-куалап һәммәсен һәм барын...

Чиләкләр чайкала, су тама – көн тулган.
Югала мизгелләр мәңгелек каршында.
Һәм сөртә иртәгә кичәдә онтылган
Куалап куылган һәммәсен, барын да...

**РАМАЗАН**

Ул китте беразга, тик кире кайтмады,
Чакырып ачуны, сизмәде ятларны.
Таптады сукмакны... Кубарып сүтәсен...
Чатнатты офыкны рамазан иртәсе...
Күләгә каплады йоклаган авылны.
Үтерде үзендә җил соңгы давылны.
Эретеп ак карны, пычракны – ак кардан,
Онтылган һәммәсен чыгарды яңадан.

Тик иртән кар явар һәм каплар һәммәсен.
Катырак янганга иртәрәк сүнәсе!
Өнемме, төшемме – урамда җил өрә.
Рамазан җылысы йөрәкне пешерә...
Булганы – онтылган, үткәне – кичәдә.
Саваплар – санаулы, гөнаһлар – үлчәүдә...
Яндырып шәфәкъта фәрештә канатын,
Йөри ак дөньяга коткару таратып...

Бу авыл ал таңда күренми гомумән.
Бу авыл таң көтми, монда таң сүрелгән...
Бугазны будырган төерне үткәреп,
Сәхәрдә, подвалда чәркәләр күтәреп,
Бу халык тормышның төбенә шуыша.
Оныткан Аллаһны, тик Аллаһ булыша
Югалган халкына, һәм азан аркылы
Көчәйтә йөрәктә үкенеч ялкынын...

**ЯШЬТӘШ**

Без килмешәк түгел, без – төп халык!
Безнең монда ата-бабалар
Туып, үсеп, илне ныгытканнар.
Монда үскән безнең калалар.
Монда алар иген иккәннәр һәм
Яшәгәннәр, яклап үз данын...
Борыл артка, яшьтәш, син күрерсең
Бу юллардан алар узганын...
Без сакларга тиеш мирас булып
Кулыбызга килгән дәүләтне.
Күтәр башың, яшьтәш, һәм горурлан!
Без, синеңчә, эзсез милләтме?..
Әйемени?
Ни сөйләгәнеңне
Ишетәме, дустым, колагың?..

Чамалабрак, мин син инкарь иткән
Милләтнең бер улы буламын!..
Һәм, кызганыч, кан кардәше хәтта
Синең кебек маңкорт-киренең...
...Тик ашыкма: «Татар үлде», – диеп,
Яңагыңа гына бирермен...

**ТАТАР ҮЛДЕ**

Татар үлде – арткы яктан килеп,
Кемдер ертты аның бугазын.
Кемдер дога кыла, кемдер тып-тын:
«Азды бит, – ди, – үзе бик азды».

Шөбһә калмый.
Әмма үле татар берни исбат итә алмый...

Алсу карда ялгыз ята егет.
Зәңгәр тапта бөтен гәүдәсе.
Ярты йөзен каплый ярым айның
Жиргә төшкән кара шәүләсе.

Һәм җан аңлый:
Бары үле татар берни дәгъва итә алмый!..

Ул сөенә – кара плащлы кеше,
Ул бу көнне ай-һай күп көтте.
Ул югалды… югалдылар бар да.
Кар әкренләп күмә егетне...

Тик плащ алдый.
Үле татар гына берни исбат итә алмый...

**УЕН**

Иртә иде... Тик бар җылылыкны
Йөрәк түгел, салкын таш алып,
Нәни бала үксеп елады да
Шушы уен китте башланып.

Язмыш сызып куйган юллар буйлап
Син финишка тып-тын атладың.
«Син – тормышым» дигән уен иде,
Син белмәдең аның шартларын.

Тузгып, тузып, узып киртәләрне,
Син яшеңне юкка коймадың.
Тик фишкалар дөрес тәгәрәде...
Ә син яшим диеп уйладың.

Инде салкын... Иртә үткән, әле
Түзәр идең бары ансына...
Башы гына кебек, әмма инде
Уен тәмам, тәмам барсы да...

**ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ИНКЫЙРАЗ**

*Мәгърур «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрен Гаяз Исхакый 1902 елда яза. Аның исәпләве буенча, төрле сәбәпләр аркасында, безнең милләтебез 2100 елларга юкка чыгачак. Ләкин Җир шары белән инде XXI гасыр идарә итә, димәк, даhи әйткән дәвернең яртысы үтелгән...*

Ялангач аяклар – саргайган чирәмнән
Без узабыз алга, онытып үткәнне.
Ярым ай яктысы югала тирәдән.
Без аны көтмәдек, ул безне көтәме?
Үлемнән бер адым, үлемгә – икене,
Нинди ак яктылык күзләрне әрнетә?
Минем бу тормышка кайтуым икеле,
Һәм минсез дә барсы тиешенчә үтә.
Без – төптә, ә милләт сулый соң сулышын,
Югалып һәм эреп, сиптереп агуын.
Раббым, оныт безне,
син бик күп булыштың!
Бу милләт теләми кабат юл табуын…

Гаеп кемдә? Әйе, калганнар гаепле!
Без чиста һәм ап-ак үзебез каршында,
Башкалар уздырды оҗмахта гаетне,
Без бәрдек ярылган башны үч ташына.
Нык торса сүзендә, нишләтә алсын кем
Салкында һәм утта чыныккан корычны?
Берләшә алмыйча таркалды күпме көн!
Үтәдекме соң без йөкләнгән бурычны?
Көнләшеп, сугышып, янап үз ишеңә,
Без ерттык тарихның тузанлы катламын.
Урын юк бу җирдә максатсыз кешегә!
Аңладым мин моны,
тик бик соң аңладым…
– Ике йөз елдан соң инкыйраз! – диделәр,
Ике йөз елдан соң бу милләт үләчәк!
Тик безнең теләкләр иркенрәк иделәр,
Ә алда йөз елдан да азрак киләчәк!
Бәлки, мин, ялгышып, булмасны сөйлимдер
Һәм батамындыр да пессимист яшендә.
Ләкин бу сүзләрдә ачу түгел минем!
Ялвару минем бу әрнүле дәшүдә!
Милләт, коткар, зинһар, үзеңне сүнүдән,
Юкса мин үземне күптәннән бикләдем.
Куркынычрак нәрсә бар бар халкың үлүдән,
Күчерә алмыйча инкыйраз чикләрен?..

**БЕР ҖЫР ГЫНА**

Бу ташларда – тарих, әмма алар
Беркемгә дә һичбер үч тотмый.
Барысы да уза, онытыла,
Ташлар гына берни онытмый...
Бу җирләрне яулар таптап узып,
Каплаганда болыт күк йөзен,
Манаралар гына сакчы кебек
Басып калды кырда берүзе...
Һәм каргалар гына манарадан
Кычкырдылар, кунып беразга;
Тик исәннәр үле иде инде
Тезләнергә соңгы намазга...

Һәм дөрләде шәфәкъ, һәм ялкынның
Күтәрелде күккә телләре,
Ялвардылар меңнәр Аллага, тик
Аллаһ үзе шулай теләде...
Барысы да моңлы бер җыр иде...
Һәм, туфракта тәне суынып,
Кылычлының соңгы авазы да
Яңгырады моңлы җыр булып.
...Һәм гомумән, тарих үзе дә бит
Бер җыр гына – тыңлый аласың.
...Тик нишләрсең – чорлар үтеп,
җырның
Туа алмый калса яңасы.

**ПОЕЗД ИЖАУГА БАРА**

Беркем беркемне дә белми,
Беркем беркемне көтми.
Кемдер юл астында калган,
Тик калганнар кул селки.
Каршыга вагон ыжгыра,
Сызгыртып сыбызгысын.
Арттан кемдер куа, нәрсә,
Узасы килсә, узсын.
Тимергә тимер бәрелеп
Рельсны юлдан кубара...
Тизлеген арттырмый гына,
Поезд Ижауга бара,
Поезд Ижауга бара...

Куркыныч хыял каршыда,
Барлык хисләр таралды.
Тукталыш – кемдер өлгерде,
Кемдер өлгерми калды.
Күршедәге һәркем йоклый,
Мин генә, ахры, уяу.
Тәгәрмәч шавы астында
Әйләнә-тирә дөнья.
Ике сәгать унбиш минут.
Тир тамып әрни яра,
Кыйбласын үзгәртми генә,
Поезд Ижауга бара,
Поезд Ижауга бара...

**ҖӘЙ**

Шәһәрдә – җылы дым. Бик эссе.
Көт тә тор: һәм әнә берәрсе
Егылыр, кояшка түзалмый.
Сарыдан кызарган нур төсе…
Башыңны идәнгә терисе…
Җәйне һәркем төрле күзаллый…

Тир ага маңгайдан, яңактан.
– Бу – ялгыш, – диләр, –
бу – зур хата!
Табигать бер бирсә, оныта.
…Әмма мин моны бик яратам:
Тир акса да маңгай-яңактан,

Таш бүлмә канны тиз суыта.

Өстәп радио һаман чыжлый:
– Бу атна үзгәреш, – ди, – булмый:
Утыздан кимеми җылылык!..
Кемдер бу нурларга түзалмый,
Җәйне кемдер үзгә күзаллый.
Көн уза бик озын тоелып...

## ГИТАРА УЙНАДЫ

Онытып барысын, шәһәр тын тыңлады –
Гитара уйнады.

Акчаларга бик мөкиббән булган
Шәфигулла агай
Сизеп алды, ахры, моны, аптырады, малай:
– Бу ни булыр... көндезге өч... йокы бирми,
Борчып мине,
Уйный, – диеп, тирен сөртеп,
Чыкты да йөгерде.

Башка ни тоймады – гитара уйнады.
Инструментта уйный иде
 Япь-яшь, ятим, сукыр малай.
Килеп җитте – тынсыз калды
Шәфигулла агай:
Берни таләп итми – ялгыз,
Һәм кичереп ул барысын,
Ныклап кыскан кулларына
тузган гитарасын...

...Шәфигулла агай яшь малайның
Яңагына берне бирде дә,
«Ярлыка» дип дога кылып,
Ашыкты икендегә...

Аннан гына бу ят көй тынмады –
Гитара уйнады.

...Ул берни тоймады – гитара уйнады.

## ИДЕГӘЙ

Син ялгызың, алда – упкын, анда –
Мәңгелекнең иркен җирләре.
Аста – ялкын, синең далаң яна,
Син илеңне үзең җирләдең...
Хәзер исә, ак төтенне куып,
Киләчәкне эзли хыялың;
Киләчәк – юк!.. Син һәммәсен әмма
Тыя ала идең – тыймадың...

Инде чиген, синең вакыт узды;
Утта як та соңгы ярлыкны,
Көбәңне ки һәм эчкәрәк яшер
Ямалмаган безнең тарихны...

Мин күрәмен – дөрләп яна дала,
Дөрләп яна еллар кайрысы...
Озакламый барсы тынып һәм бу
Инде соңгы ялкын, ахрысы...
Мин иртәне көтмәм, көтмә син дә!
Алда упкын, инде сүн илдәй!
Мин сикердем... Ә син... Сиңа авыр
Бу адымны атлау, Идегәй...

* * *

Ни әйтим,
ни дәшим,
ни тойыйм,
Һәммәсе дә ачык булганда?
Тын гына яшерәм корольне мин,
Тик читтә йодрыклар болгана.

Мин урта хәлле
    шахмат
        фигурасы:
Пешка, фил яки ат – бер оя...
Көндәшнең
    ладьясын
        җиңалам мин,
Тик соңрак...
Миңа ферзь мат куя.

## ДОГАҢНАН КАЛДЫРМА

Яңаралар кичен хәтердә мизгелләр.
Һәм карый чагылыш ватылган көзгедән.
Пышылдый кемгәдер коелган йолдызлар.
Йөрәк шашмый күптән, димәк, ул да тузган...
Адашкан һәм йөри хисләр юл эзеннән,
Түзәргә иде дә, ярыйсы түзелгән.
Барсыннан соң әмма кабат мең түзәргә
Миңа һәрвакытта иманым көч бирә.

Ал шәфәкъ офыкта әкренләп сүнгәндә,
Һәм якты дөньяны күмгәндә күләгә,
Тәрәзә алдында, искәреп һәр кичен,
Дога кыл, карчыгым, минем дә җан өчен...
Урамда котырып яңгырлар яуганда,
Адашып калганда кичәге буранда,
Искәреп һәр кичен намазлык алдында,
Карчыгым, син мине догаңнан калдырма!..

Мин җавап булалмам йөрәгем эчендә,
Вөҗданым сорау күк батса үз үченә,
Һәр сулыш санаулы, һәр адым – бер сулыш,
Мәңгелек – бер мизгел, ә тормыш –
                                    зур сугыш...
Бу сугыш эчендә шәүләләр көрәшә,
Һәм шушы сугышны кадерли бу шәһәр.
Ләкин һәр адымнан хәл кимеп барырга,
Иңбашка кунганда кар... Ап-ак кар гына...

Карчыгым, син мине доганнан калдырма,
Карчыгым, доганнан, доганнан калдырма,
Доганнан калдырма!..

**ӘНКӘЙ, МОҢАЕП КАРАМА**

Әнкәй, моңаеп карама һәм түкмә син яшеңне,
Син язмышка берәр кайчан ярдәм сорап дәштеңме?
Ярдәм иттеме сиңа ул, коткардымы упкыннан?
Ә миңа әйтәләр бары: «Ычкын моннан,
кит моннан».
Һәм һәрвакыт үзем генә сүндерәм мин ялкынны,
Сагыш җанны кимерергә минем йөрәккә кунды…
Мин күптән хыялсыз яшим – җанымда минем
богау,
Әйт, әнкәй, гаепмени ул башкалар кебек булмау?..
Хәзер барсы үзгәрде шул: кем хиссез,
шуңа кулай.
Ә без инде һәммәбез дә акылдан яздык бугай…

*** * ***

Бер көн үтте.
Алсу таңнан алып
Кичкә кадәр акты яктылык.
Кабат тамды каткан җиргә саф яшь,
Кабат типте йөрәк
Атлыгып...
Бер көн үтте.
Тагын якты бер көн.
Кояш нурын бозга яшереп,
Үтте бер көн,
Ап-ак карын сибеп,
Ап-ак буран булып үкереп...
Үтте бер көн.
Сүнде көнбатышта
Әйтерсең лә кызган ташкүмер;
Киртәләргә таулар өеп,
Үтте...
Бер тәүлеккә сыйган бер гомер...

**ЯРА**

Көн артыннан көн үтә дә,
төн артыннан төн үтә.
Күңел генә талпына да,
олы үзгәреш көтә.
Бер почмактан бер почмакка
кемнәр ни генә йөртер –
Җөмлә тәмам, тик ахырда
нокта түгел, ә өтер.

Әмма ни файда гомреңнең
сукмагын табалмагач,
Каны күпергән ярага
бөртек күкерт калмагач?
Яна күңел, яна йөрәк,

булмаса да учагы!..
Тимәгез йөрәккә – бүген
анын елаган чагы...

Ай чыгып югала күктән,
каплый болыт кояшны.
Бөтен булган куркулар да,
кызганыч, чынга ашты.
Гасыр тончыкты үзенең
үтәлмәгән антында...
...Һәм басып торам мин ялгыз
җиде юлның чатында.

Авырткан чагы йөрәкнең...
Суланган һава сулап,
Кан урынына агу ага,
бөтен тәнне агулап.
...Күз алды караңгыланды,
һәм бар бетәсе бетте...
Ә яраны дәваларга
юк бер шырпы күкерте...

*** * ***

Мин яралы –
Зәңгәр күккә
күтәрми канатларым...
Шуны аңлап, мин тын гына
киләчәккә атладым.
Инде күзәтеп Вакытның чоңгылы ишелүен –
Тормыш гөлләр өләшкәндә,
Богаудан чишелүем...

Төн кирәк...
Төнне көтәм мин...
Һәм гомер буе көттем.
Кызганып, һәр кимчелекне
яшереп кала ул төн...

## КАЯ ЧАБАСЫҢ СИН...

Кая чабасың син, тормыш дигән
Бу язмышның чиксез елгасы;
Күпме әле синең дулкыныңда
Миңа батып-батып агасы?..

Ярларыңа атмыйсың ичмасам,
Мин хәл алыр идем – бер сулыш!..
Ник йөрәгем урын тапмый минем,
Ник күңелем бушлык кебек буш?

Дөнья матур! – Ялгыз калган чакта
Мин һаман да ныграк тоямын:
Ялгыш исән калган бер кошы мин
Күптән җимерелгән ояның...

## МИН ҮЗЕМӘ УРЫН ТАБА АЛМЫЙМ

Мин үземә урын таба алмыйм!..

Кем мин –
Зур халыкның
Читтә калган ятим улымы?..
Бу язмышны язучы берәүме,
Әллә аның
Уенчыгы
Яисә колымы?
Минем юлда үтмәс упкынмы ул?
Каберме йә мине күмәргә?
Мин һавада айдай янармынмы?
Хакым бармы яшем түгәргә?
Ни идарә итә минем белән –
Гакылмы
йә
Аңсыз теләкме?
Язмыш яшәр өчен биргән гомер –
Тәүгесеме,
Соңгы бүләкме?..

Мин үземә урын таба алмыйм...

*** * ***

*(Есенин мотивлары)*

Син таш атма башка миңа көлеп
Һәм тоз сипмә кипмәс ярага.
Ераграк тор, якын килмә бары –
Мең гасырлар безнең арада...

Каргама да, каргыш төшми миңа,
Абындырма, ләкин бар алдан.
Бу көн үтсен, ә иртәгә инде
Мин башлармын барсын яңадан...
Тик өшетмә боздай каткан тәнне
Һәм хәтерлә: тапмый калып юл
Юкка чыккан – югала алмый һәм
Янган кабат яна алмый ул!..

## ЭЛЬДОРАДО

Бу җирдә күк күптән каралган,
Бу җиргә төшми ай яктысы.
Бу җирләр уратып алынган,
Бу җирләр – дөньяның яртысы...

Монда юк... Өмет юк, бәхет юк,
Монда юк йолдызлар, юк кояш.
Мондагы йөрәкләр – токтында,
Мондагы йөрәкләр – каткан таш.

Монда көн җылынмый – гел суык,
Монда юк шәфкатьлек шәүләсе.
Монда йә яшисе кол булып,
Монда йә кол булып үләсе.

Монда җил җаннарны өшетә,
Ә упкын ишелә тирәнрәк,
Монда һәркем өскә үрмәли,
Тәгәрәп төшәргә бергәләп.

Монда юк... Тормыш юк, яшәү юк...
Монда һәр тамчы су тоз тулы.
Мондагы баткаклык буенча
Җәелгән тәмугның тар юлы.

Монда һәркем узган вакытта
Йодрыклап тота гел үз кулын.
Һәм тып-тын пышылдый үзара:
«Бу синең ватаның, онытым...»

**КАЙТУ**

Мин өемдә.
Рәхәт.
Тәрәзәдән
Исә көзнең салкын таң җиле.
Ачык ишек,
Шыгыр-шыгыр килеп,
Уятырга телидер мине.

Ә мин тордым инде.
Өстәлләрем
Китап-дәфтәр белән тулганнар.
Ак бит аунап ята.
Кара – беткән.
Тышта җем-җем килә тәүге кар.

Ут яктысы төшә ак түшәккә.
Җыелмаган юрган,
Ак мендәр
Ашыкмыйча,
Сабыр итеп кенә
Көннәр буе мине көткәннәр.

...Зур йолдызны тартып алалдым мин,
Кәкре юлны
Тартып турайттым...
Син сүнмә, шәм,
Ашыкма, таң.
Елама, җил –
Кайттым мин,
Кайттым.

*** * ***

*2006 елда, Удмуртия Республикасы*
*Россиягә үз иреге белән (!) кушылуның*
*450 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә язылды.*

Күршеләрдә олы бәйрәм бүген –
Дүрт йөз илле еллык юбилей.
Россиягә кушылганга менә
Шуның кадәр үткән икән, әй...

Олы дата... Меңьеллыкның бит ул
Нәкъ яртысы, соң, нәкъ яртысы!
...Һәм күзләрдә янган утлар, димәк,
Түгел горурлыкның яктысы...

Кая мантыйк монда, йә, кем әйтер,
Кая монда якты килер көн? –
Сыңар гына калган милләт үзе

Югалуын бәйрәм иткәчтен...

## ЕЛГА БУЕНДА
## ТОРМЫШ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

Дулкыннар ярын юалар мең ел аккан елганың.
Ул хәзерге белән яши, киләчәге юк аның!..

Һәм сулары диңгез суы белән кушылган чакны,
Горур мизгелләр шәмендә сүрелә соңгы чаткы...

Дулкыннар ярын ишәләр мең ел аккан елганың,
Үткәне ак томаннарга кереп югалган аның.

Кирәкми аңа үткәне!.. Аңа ансыз да яхшы...
Ул ага – ирекле елга – бар ярларыннан ташып...

*** * ***

Йөзәр еллар аша үтеп,
Ут-судан исән калып,
Җан агуны учлап ашап,
Газиз йөрәген ярып,

Ярасын тегеп яшь белән,
Җитмеш ямап хатаны...
Туган телем сау калды да,
Инде үлеп ятамы?!

*** * ***

Тимә, дәшмә,
Юатма да,
Син башкаларга кирәк, –
Күңеле бушап калганчы
Еласын әле йөрәк...

Яшь – яраны дәвалый ул,
Чыгара пыяласын...
Бәлки, кайгысы юылыр,
Еласын ул,
Еласын...

*** * ***

Ялгыз торганда
Кышкы буранда,
Җил котырганда,
Пышылдаганда:
– Беттең син... Беттең!..
Йөрәгең... тып-тын...

Саламга тотын!

Бу, соңгы булса да,
Барыбер бар булган өметең...

## 1552 ЕЛ

Төн җитте һәм болыт арасына
Яшеренде, куркып, ярым ай.
Төн тып-тыныч, әлеге көз өчен

Бу төн иң-иң шикле төн бугай...
Төн кап-кара, һәм калтырау хисе
Биләп алган бөтен Казанны.
Кол Шәрифтән аваз килми – имам
Әйтеп бетермәде азанны...
Җиле дә юк... Тик еракта гына
Тояк тавышлары ишетелә.
Димәк, сугыш, димәк, урыс яклап
Казан тарафына яу килә...

Әлеге төн артык иртә бетте,
Артык иртә бетте барсы да!
Үлеме дә килмәс кебек иде,
Ә хәзер ул синең каршыңда...

Атлар кешни, кара болыт кебек,
Тирә-юньне дошман урады.
Кулдан төшеп китте бәллүр савыт, –
Яхшылыкка диеп юралды...
Юралды да, чынга ашмады шул,
Җир тетрәде аяк астында.
Тормыш белән үлем авазлары
Буталдылар бергә барсы да...
Суеш һәм акырыш... Әйтерсең лә
Дөнья бетә – Хөкем көнедер!
– Алла! – диде хан һәм аягына
Тәгәрәде башы кемнеңдер...

Әлеге таң артык соңга калды,
Артык соңга калды барысы!
Артта үлем, алда үлем, инде
Кайсы якка каршы карыйсы?
Юк, барсы да болай бетә алмый,
Барысы да яхшы булачак!
Ник кол булсын татар? Иртәгә үк
Ул дошманны моннан куачак!
Ә башкача бары мөмкин түгел,
Кая мантыйк монда, алайса?
...Бу тормышта мантыйк юк инде ул,
Әгәр алай уйлап карасаң...
Тик нигә соң дошман камый һаман,
Тик нигә соң артка чигәбез?!
Юк, җиңәбез дидек бит инде бер,
Димәк, иншалла, җиңәрбез!..

Әлеге көн артык озак уза,
Артык озак уза барсы да!
Үлем кайчан килер кебек иде,
Ә хәзер ул әнә – каршыңда...

* * *

Иртә җиткән, тәрәз шәүләсеннән
Тар бүлмәгә якты көн төшә.
Әллә ничек бүген – җанга авыр,
Әллә ничек шунда – төрлечә...

Ә тыш якта буран, һәм ап-ак кар
Тып-тын ява шәрә урамга.
Һәм өшегән кулын уа-уа,

Сукбай сеңел хәер сорана...

Начар түгел кебек, яхшы түгел.
Һәм, бәлки, бу иң-иң яманы!..
Бер чокыр чәй һәм бер шакмак шикәр –
Өч сәгатьлек бөтен калганы.

Җил миләштән кошчыкларны куа.
Тәрәзәдә – салкын буяулар.
Ак чыршылар талган ботагыннан
Әкрен генә сагыш коялар...

Йөрәк җебе хәзер өзеләчәк,
Кирәгеннән артык тартылган...
...Гомер генә ипләп агып бара
Узып киткән трамвай артыннан...

**УЛ КИЛЕР**

Ул килер дә алып китәр мине –
Үлем. Тып-тын аңа ияреп,
Мин барырмын Раббым каршысына...
Шул вакытта нәрсә диярмен?
Сүз табылыр микән акланырга?
Гафу итәр микән Ул мине?
Гафу итәрменме үз-үземне,
Гафу итәрменме?.. –
Белмимен...

Кошлар әкрен генә китеп бара,
Мин очармын әле, очармын!..
Бүген генә сагышыма батып
Яшь түгәргә ялгыз дучармын...
Барсы узар... начар бер төш кебек...
Һәм яшьнәрмен күкрәп, яшьнәрмен!
Кеше кебек яши алмадым мин,
Бәлки... соңрак әле яшәрмен...

Әле башы гына һәммәсенең,
Әле әллә каян көч килә...
Тик мин инде ияргә әзер
Югарыдан иңгән Илчегә.

Ә ул килер, һәм чакырып мине:
– Әйдә, – дияр, – вакыт ашыга.
…Ни әйтермен әмма ялгыз калып,
Ятим калып Раббым каршында?..

Гомер буе мин бары җыр яздым,
Һәм җыр булды минем гомерем.
Кеше салкыннарда юрган япса,
Мин хыялга гына төрендем…

Мине юрган гына җылытмады!
Җылытмады салкын карашлар…
Кемдер, бәлки, минем бу сүзләрне
Бер укыр да көләр дә ташлар.

…Бик күп нәрсә тәмамланмый калды,

Шуның өчен генә эч яна…
– Ни эшләдең? – дисә, горур басып,
Мин бары тик... җырлармын Аңа...

**АКРЫНРАК АК, НОКРАТ**

Тирә-юнь тып-тыныч, кошларның да
Күптән тынды инде тавышы.
Дөрләп янган кояш тоныкланды.
Көн әкренләп кичкә авышты.
Аннан-моннан җиле генә исеп,
Тибрәндереп китә хисләрне.
Җанга авыр чакта исмәде бит!
Исмәде бит шунда, исмәде...
Хәзер генә, шәфәкъ яктысында
Тынгы бирми, борчый талларны...
Бу көн үтте, тик иртәгә көн бар...
Ә яшәргә җегәр калмады...
        Бер тамчы да җегәр калмады, –
        Тик анысы соңрак, аннары...
Акрынрак ак әле, Нократ, зинһар,
Бераз гына кимет тизлегең!..
Өч тиенгә генә артты тормыш...
Иңбашларга бик нык сизелде...
Алай ашыктырып кума әле,
Зинһар өчен, бераз көттерим! –
Җырым кала, җырланмаган җырым!..
Шуны гына җырлап бетерим...

Әллә инде барсын яңабаштан
Башлыйсы бер, җиңне сызганып?!
Иснәп кичәгедән басылмаган
Май аеның тормыш тузанын...
Тирне сөртеп маңгай сырларыннан,
Яшь аралаш күреп кояшны!..
Тик булырмы иске хәрәбәдә
Яңа хыял белән урнашып?
Ай-һай, белмим... Әмма Нократ ага
Һаман, юып иске ярларын...
Юк, яшәргә кирәк, тик яшәргә!
Җанда гына берни калмады...
        Бер тиенлек берни калмады...
        Ләкин барсы соңрак, аннары...
Кабаланма, Нократ, акрын, зинһар,
Бераз гына кимет агымың...
Нигә синдә дә соң чагылышы
Ягымлының гына ягымлы?
Алай ашыктырып кума әле
Бу тормышны, бераз көттерим!
Вәгъдәм кала, шул вәгъдәмне генә
Ахырына кадәр җиткерим!..

Төн сагышлы. Йөрәктә дә сагыш.
Тик бу моңсулану түгел, юк!
Гел уфтана дигәч тә, барысы
Начар түгел инде алай ук.
Иләшеп кенә булмый һаман
Һәр көн кабатланган шау-шуга,
Ничек акыл чыкмый диген баштан

Инде моның кадәр шашуга...
Юк, түзәрлек әле, болай гына...
Аерып була актан караны...
Әллә инде ал таң атып килә?!
Нәкъ шулай бит!.. Тик ник караңгы?..
        Һәммәсе дә соңрак, аннары...
        Һәммәсе дә соңрак, аннары...
Инде тукта, Нократ, бераз хәл ал,
Бераз кимет агым барышын!..
Юкса бит ияреп бара идем, –
Әзрәк кенә артка калыштым.
Алай ашыктырып кума әле,
Ачуланма, бераз көттерим!..
Гомрем кала, яшәлмәгән гомрем!..
Шуны, зинһар, яшәп бетерим...

**ХУШ, ЯР ЧАЛЛЫМ**

Хуш, Яр Чалым! Китәм. Инде гелгә.
Сау булып тор. Мине көтәләр...
Бу юлларым сиңа илткән иде,
Инде хәзер синнән илтәләр...
Сау булып тор, иң шәп елым минем,
Сау булып тор, янган филиал...
Монда калган бәхет-сагышларым,
Сау булып тор һәм сау булып кал!..

Сагынырмын инде, сагынырмын...
Чирәмеңнән узган көннәрне,
Карларыңны ертып атлаганны,
Йоклый алмый яткан төннәрне;
Сөйгәнемнең: «Рүзәл, сәлам!» – диеп,
Онытылмас тәүге карашын...
Бер утырып уфтанасы килә,
Эх, бу вакыт, кая барасың?..
Тәүге тапкыр назлап-иркәләвен,
Һәм ут кебек чыгып алдыма
Мине кочып пышылдавын:
– Зинһар,
Бүген, – диеп, – ялгыз калдырма!
Киң проспекттан эре атлавымны,
Дүрт кешелек кысан бүлмәне
Сагынырмын инде! Барсы болай
Бик тиз узар диеп белмәдем...
Төннәр буе гитара кылларын
Уйнаттырып үткән айларны
Инде хәзер каян эзләп карап,
Инде хәзер каян табармын?..

– Алло, нихәл, дустым?..
– Яхшы гына…
Үзеңнеке?..
– Әле ярыйсы...
Казангамы быел?..
– Алла бирсә...
– Ник Чаллыда гына калмыйсың?
– Сайлау мөмкинлеге тигез түгел...
– Шулайдыр да...

– Шулай...
– Булмаса,
Ак җәймәләр, димәк, юлларыңа,
Ак җәймәләр, димәк, алайса...
– Рәхмәт.
– Сау бул. Исән бул үзең дә...

Син дә сау бул, Чаллым, һәм әгәр...
Мөмкин булса, кайтырмын әле мин!
Тик әлегә мине... көтәләр...

## II бүлек

***Син минем тормышым, ә мин***
***Тормышымны яратам...***

### БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ

Көзгегә карыйсың, чәчеңне тарыйсың,
Мин беләм – син бүген кичәгә бармыйсың.
Һәм, сөртеп ирнеңнән кып-кызыл иннекне,
Йокларга ятасың, сихри төн – синеке.

Урамда дусларың шаулаша, әмма ай
Бүген кабат сине күрә алмый бугай.
Тәрәздән генә ул елмаеп гүзәлгә
Ялтырар, ә сиңа… Син тиеш түзәргә.

Көзгегә карыйсың, һәм синең күзләрең
Тамыза ачы яшь, танымый үзләрен.
Син елыйсың, ә ул янында ук сөйли:
«Дөньяда син ялгыз, сине беркем сөйми!»

### СИН КИТТЕҢ

Мин яраттым сине, әмма сөю
Сүнде инде диеп әйталмыйм.
Мәхәббәтне саклый алмадым шул,
Һәм син киттең, сине мин аңлыйм.

Тик бу хисләр сине борчымасын,
Мин теләмим яшең күрергә.
Мин җылылык бируалмадым сиңа,
Әмма кирәк булган бирергә!

Әмма кирәк булган яратырга
Үбеп-кочып, янып сөюдә.
Тик нишләтим – җилләр генә уйный
Без биегән җырның көенә.

Һәм син киттең... Сине кемдер коча,
Син гел башка утта янасың!
Син бәхетле, яңа парың гына
Мин сөйгәннән ныграк яратсын...

## УН МИНУТСЫЗ УНБЕР

Сәгать унга кыз килергә тиеш
Мәхәббәте – яры янына.
Әмма инде ун минутсыз унбер,
Ә чибәркәй бары уяна.

Ул аңлатыр аңа: «Мин авырдым,
Табибларда булдым иртән», – дип.
Яки әйтер: «Мин ялгышып тәмам
Сине башка җирдә көтәм», – дип...

Ни әйтсә дә, әле вакыт иртә,
Көн башлана гына түгелме?
Әле иртә – стенадагы сәгать
Ун минуттан сугар унберне...

## АТЫНГЫЧ

Җил узды арадан, һәм ике ягында
Без калдык бергәләп атлаган юлларның.
Син башың идең һәм дәртләнеп тагын да
Йөгердең алгарак, калдырып калганын.

Син миңа һәммәсен аңларга булыштың.
Тик озак вакыт мин килмәдем аңыма:
Таганнар атынды... Син тиз-тиз шуыштың
Әтиең булырдай чит ир-ат янына.

Атынгыч әйләнә – әйләнәсез янә,
Ә мин бар дөньямны бер мәлдә югалттым.
Тик таган әйләнә, бәйләнә-бәйләнә
Яраттым шул сине, артык нык яраттым!..

Бөркү көн эретте хисләрнең ачысын,
Һәм кичке эсседә сезнең сын тарала...
Күзләрдән акмаган кайнар яшь тамчысы
Йөрәктән тәгәрәп, йөрәккә кадала.

Мин киттем... Артымнан үзеңне дә көтеп,
Син борылмадың да, буласы булмады.
Һәм янса да йөрәк, хисләрне дөрләтеп,
Сөюдән янмады, янмады, янмады!..

Ә таган әйләнә...

## САБЫЙ ФӘРЕШТӘ

Мин автобустан төшүгә,
Син яныма киләсең.
Мин сиңа нидер сөйлимен,
Син нидәндер көләсең.
Син конфет тәкъдим итәсең,
Мин, әлбәттә, баш тартам.
Ә иң якын дустың миңа:
– Ул, – ди, – сине ярата...

– Сизмисең дәмени, – ди ул,
Ә мин барысын беләм.

Әле классташ малайларың
Көнләшә, ахры, миннән.
Ялгышалар, хәтта син дә
Ялгышасың, ахрысы.
Шулчак эндәшә иптәшем:
– Әйдә, киттек, абыйсы...

Сиңа бит әле, матурым,
Үсәсе дә үсәсе.
Мин инде карт, сиңа менә
Тик унберләр тирәсе.
Син үс, мәктәпне тәмамла
Һәм күп укы китапны,
Алда, бәлки, кавышырбыз,
Тапмасаң яхшыракны.

**ЮГАЛТАСЫМ КИЛМИ МИНЕМ СИНЕ**

Миңа ак кыш бирде сине, тып-тын
Учларыннан җиргә төшереп.
Ә урамда ак кар ява иде,
Син ак идең, шушы кар кебек.
Йөрәк шашып типте, керфегеңнән
Кар бөртеге кунып иңемә,
Ак кыш буйлап, кулга-кул тотынып,
Без атладык сөю иленә...

Югалтасым килми минем сине!
Күзләремне синең күзеңнән
Аерасым килми, кил якынрак,
Мин җибәрмим сине үземнән.
Югалтасым килми минем сине!
Аңламавың барсын икеле:
Ак карларга кереп китәрсең дә,
Табалмамын кебек шикелле.

...Ә кар учта эри әкрен генә.
Һәм типкәннән-тибә йөрәгем.
Һәм флейталар кебек уйный җилләр
Ак фасылның ямьле көйләрен...
Мин әйтергә тиеш иң мөһимен,
Өстәп кышның шушы көенә:
Мин яратам сине, ә син, зинһар,
Каршы килмә минем сөюгә…

Югалтасым килми минем сине...
Күзләремне синең күзеңнән
Аерасым килми...

**МӘХӘББӘТ ҺӘМ СУГАН**

Без сөйләштек очрашырга
Анда – елга ярында.
Шунда төшеп бара идем
Мин абына-абына...

Түтәлләр аша узганда
Чәчәк җыярмын диеп,

Кул ялгыш тюльпан урнына
Суганга китте тиеп.

Алдым, каптым. Пакь киемнән,
Чәчәк – күкрәк түрендә.
Саф һавада суган исе
Хушбуй белән үрелә.

Нишләдем мин! Төшкәч кенә
Аңыма килдем, ахмак!
Сиздермәскә тырыша, тик
Читләшә сөйгәнем – хак.

Ә ис бетми – нишләтим соң,
Нидер җанга шом сала.
Авыз ябык – тик ис чыга
Борын аша булса да.

Мин сүз тапмыйм – минем күзләр
Иркен болынны айкый.
Ул борыла, мин тиз генә
Су алып авыз чайкыйм.

Ул борыла, ә мин аңа
Дәшәм шыңшып: «Яратам».
Ул якынрак килә, ә мин
Сүз байлыгын югалтам.
Иреннәренә үреләм,
Ә ул миннән читләшә.
Мин аңа – сөйгәнем миннән...
Бездән суган көнләшә.

Түзә алмады, әлбәттә,
Кайтып китте, һәм беләм,
Мин гаепле, ялгыз калдым
Суган кыягы белән...

Җан янды, тик үтте барсы,
Сүнгән хис котырмагач.
Нишләтәсең, мәхәббәтең
Суганлык та тормагач.

## КАЛМЫЯ БУЕНДА

Җылы кояш һәм тар елга буе.
Чәчәкләр һәм кошлар тавышы.
Менә кабат синең зифа сының
Минем янга таба авышты.

Яшел чирәм һәм зәңгәр күк йөзе –
Шәфәкъ ташый чиктән түгелеп.
Без югалабыз, югала дөнья,
Шушы гүзәллеккә күмелеп.

Тын болынлык – авыл артта калды.
Текә ярлар безне яшерә...
Һәм бер-берсен тыңлап, бергә тибә,
Бергә яна ике яшь йөрәк.

Синең иреннәрдә чия тәме

Җаным-тәнем белән мин тоям:
Син – минеке, син янымда минем,
Тик безнеке генә бу дөнья.

**МИН СИНЕ ЯРАТАМ**

Учымда шәфәкъның ахыргы утлары
Сүрелә әкренләп, якты көн туктады
Егерме сәгатьтә һәм басып ярсуны
Яңадан биләде йөрәкне моңсулык.
...Таң атар, син торып урамнан үтәрсең,
Мин көтәм һәм беләм – син дә нык көтәсең,
Мин сине яратам, яратам, акыллым!..
Чакрымнар, урамнар, урманнар аркылы.
Моңланса да бу җил елатып күңелне,
Чикли алмый минем сүрелмәс сөюне...
Мин сине яратам һәм дәшәм үземә:
– Беразга гына түз, беразга түз генә…

Шәфәкъның утлары учымны пешерә.
Хәзер кемдер йоклый һәм татлы төш күрә.
Ә минем тормышым, син булсаң янымда,
Мең төштән татлырак – янәшә бул гына.
Кулыңа кагылам һәм кысам учыма –
Төш түгел! Тик минем күзләрем ачыла…
Мин сине яратам, ләкин син, акыллым,
Еракта – урамнар, урманнар аркылы.
Тик иссә дә бу җил елатып күңелне,
Чикли алмый синең сүрелмәс сөюне…
Мин сине яратам һәм дәшәм көзгегә:
– Беразга гына түз, беразга түз генә...

**СӨЙГӘНЕМӘ ХАТ**

Исәнме, матурым минем!
Яхшыдыр бит барысы?..
Кәеф ничек? Ничек хәлләр?
Ә минеке – ярыйсы...
Хат язарга булдым менә.
Һәм йөрәгем дәшкәнне
Әкренләп бу биткә терким.
Ә син... син укы, яме?
...Саубуллаштык та беразга,
Аерылды бер тормыш.
Тик син укы, һәм... һәм, зинһар,
Ачуланмаска тырыш...

Безне кыш бербөтен итте,
Салкын фасыл, әйеме?
Тик шул салкыннан башланды
Минем тормышым яме.
Кыш миңа бу дөньядагы
Иң-иң булган кыз белән
Яңа сулыш бүләк итте –
Син беләсең, мин беләм,
Кыш белә. Тик безнең сөю
Эретте аның бозын.
Һәм язгы Чаллы юлларын
Мин синең белән уздым...

Яз болай да ямьле мизгел,
Ә синең белән әле
Мең тапкырга артты бу ямь!
Тик моны җәй белмәде...
Бәйрәм узды, аның белән
Узды җилләр агышы...
Һәм бу биткә тамыза көн
Ялгызлыкның сагышын.
Сәер, әмма һәммәсеннән
Шундый җиңел тыелып,
Мин үбәм шул җилләр шавын,
Сине үпкәндәй булып...

– Мәхәббәт турында җырлар,
Шигырьләр беткән, – диеп
Кем әйтте соң әле? Ул да
Карасын иде сөеп!
Чын мәхәббәт белән янып,
Иң югары ноктада
Ике сукмак аерылгач
Ике ят якка таба,
Бу сүзләрен ул үзе үк
Яше белән эретеп,
Мин сине көткән шикелле,
Саргаер иде көтеп...
Тик без бергә... Күп чакрымнар
Башканы расласа да,
Йөрәкләр бергә тибә һәм
Йөрәкләр бергә яна...

Сагындым мин сине... Кемдер
Елмаер иде бары:
– Санаулы көн эчендәме?
...Санаулы калганнары...
Ә мин сагындым, һәм хәзер
Сүз артыннан сүз өстәп,
Үткәннәргә борылам да
Шул үткәннәрне көтәм...

Әби-бабай ничек анда?
(Ачулансалар, тизрәк,
«Ялгыш укыгансыз» диеп,
«Әни-әти»гә төзәт...)
Һәм сәлам әйт һәммәсенә
Йөрәгемнең түреннән.
...Әле тынгы бирми, янда
Сеңелкәшем үрелә.
– Миннән дә сәлам әйт! – ди ул.
Һәм мин әйтәм:
– Сеңлемнән
Кайнар сәлам сезгә!
Димәк,
Сәлам ике күңелдән...
Килер бер көн... һәм без бергә,
Бары өскә ургылып,
Икәүләп таптап үтәрбез
Киләчәкнең киң юлын...
Һәм мин сине нык-нык кочып,
Күзгә төбәп күзләрне,
Колагыңа пышылдармын

Бу хаттагы сүзләрне...
Ә алар кими әкренләп,
Ни әйтим соң азактан?
Димәк, болай... Мин инде бер
Әйткәннәрне яңартам:
...Тәртипле йөр – иң мөһиме,
Һәм сак бул – бу мөһимрәк.
Онытма, син ялгыз түгел,
Яныңда – минем йөрәк...
Авыр булган минутларда
Юатыр ул һичшиксез...
Беләм, минсез читен сиңа,
Миңа да читен синсез!..
Сәламәтлегеңне сакла...
Әйтеп бетермәгәнне,
Тик әйтәсе булганнарны
Әниең өстәр әле.
Ә мин шушында төгәллим...
Һәм кабатлыйм кабаттан:
Син минем тормышым, ә мин
Тормышымны яратам...
Мин ышанам сиңа, инде
Искәртмичә калганын,
Иң изге теләкләр белән,
Иркәләп үбеп,
Җаның.

* * *

Миләш ачы, диләр...
Миләш ачы.
Ә мин таптым иң-иң татлысын!
Тик салкыннан саклый алырмынмы?
Әйтә алмыйм менә анысын...

Миләш ачы...
Ничек, шулай булгач,
Гел башкасы үскән юлымда?
Менә ич ул – үреләсе генә –
Һәм тәгәрәр ике кулыма.

Миләш ачы, диләр...
Бәхәсләшмим.
Һәм бу миләш миңа тиешле!..
...Әмма, гафу, ихтыярым җитми
Өзәргә бу татлы җимешне.

* * *

Мин ялгыштыммыни шашып сөеп,
Яшь аралаш үбеп-яратып;
Бу мәхәббәт ник яндыра хәзер,
Ник әрнетә, җанны каралтып?

Ник тынгысыз, кая бәрелергә
Белми йөрим, батып үземдә...
Эх, йөрәгем, нәрсә эшлим инде?
Эх, йөрәгем, зинһар, түз генә...

Сабырлыгым күпме микән әле?

Күпме микән әле көчем дә?..
Мин ялгыштыммыни, сөюемне
Үтермичә саклап эчемдә?..
Ник тилмертә мине синнән өргән
Түзалмаслык ачу һәм салкын?
...Менә гөлгә күмим диеп сине,
Йөрәгемне кабат канаттым.

...Күзне йомсам, иреннәрең тәме
Исләремә төшеп җәфалый...
Ник шулкадәр сөям, һәм шулкадәр
Ник сөяргә сине ярамый?..

**ГҮЗӘЛЕМ**

Күпме йолдыз – күпме хыялландым
Мин йолкырга сиңа бирәрсен.
Ак фәрештә булып һәр төн саен
Төшләремә нигә керәсең?..

Мин оныттым сине – нигә һаман
Аңламыйсың шуны, гүзәлем?
Мин хәзер башканың насыйп яры,
Мин хәзер башканың Рүзәле...

Ник тилмертәсең соң, шулай булгач?
Бәгыремне нигә сыгасың?
Ник фәрештә булып һәр кич саен
Алларыма килеп чыгасың?..

Кыен миңа!.. Ник бер хатам өчен
Шулай тилмерергә тиеш мин?
...Искә төшмә, зинһар, беләсең бит –
Яшь чыгару миңа килешми...

**БАШКАЛАДА УЛ**

Син әле генә каяндыр
Мәтәлдең кайтып.
Кояш сүнде, ай кабынды –
Йокларга вакыт.
Ләкин синең керфекләрең
Йомылмый әле:
Йөрәгеңдә – гүзәлләрнең
Иң-иң гүзәле...

Тилмермә, гороскоплардан
Очрашу юрап:
Меңьеллык башкалада ул –
Аралар ерак...
Өстәлдәге чынаякта
Чәйләр суына...
Кулларыңны канат итеп
Очасы гына...

Бар дөнья караңгыланды,
Сүрелде шәфәкъ.

Һәм күмелде моңсулыкка
Син торган шәһәр;
Әмма һаман да якты ут
Төшә бүлмәңнән.
Димәк, синең хыялларың
Әле сүнмәгән.

Гороскоплар ни әйтсә дә,
Тилмермә юрап:
Меңьеллык башкалада ул –
Аралар ерак.
Күпме бикләми йокласын
Йорты келәсен –
Очраша алмавыгызны
Яхшы беләсең.
Ул, бәлки, ялгызы хәзер
Күккә карыйдыр.
Һәм иң якты йолдызларда
Сине таныйдыр.
Һәм, бәлки, яшен сөртәдер
Үзен юатып.
Ләкин инде соң һәм салкын –
Йокларга вакыт...

**ҖАНЫМНЫҢ ЯРТЫСЫ**

Без икәү язмышны үзгәрткән көннәрдә
Язмышлар икән шул үзгәрткән барысын.
Һәм тәүге кат сиңа «Яратам...» дигәндә,
Калдырдым мин синдә җанымның яртысын.

Әле күп тә түгел янымнан киткәнгә,
Әле юк яраны ни белән ямыйсы?
Еракта син миннән, тик анда, читтә дә
Оныталмый сине җанымның яртысы.

Һәм ялгыз калуның йөрәгем бу төндә
Аерылу икәнен ник аңлый алмый соң?
Тибенә, тынгысыз, ә аның эчендә –
Син миңа калдырган... җаныңның яртысы.

**ТӘҮБӘ**

Һәммәсе дә ничек башланды бит:
Ялгыш кына тиеп киттем дә,
Гафу үтенмим дип борылдым һәм
Нурлар күрдем синең битеңдә.
Син елмайдың...
– Нәрсә, – дигән булып, –
Әллә арба тагып йөрисең?
Күктән каргаларны санап атлап,
Аста ниләр барын күрмисең...
Һәм күз кыстың...
Ә мин айныганчы
Син юк идең инде каршыда...
Эх,
Һәммәсе әллә кайчан булган –
Бүген генә кебек барсы да…

Соңрак сезгә килдем…
Чәчәк тотып,
Конфет тотып,
Костюм-чалбардан…
Ишек кактым,
Һәм алиһә үзе
Миңа ишек ачты яңадан…

– Ә мин сезне беләм бугай кебек…
– Ә мин сезне белмим нигәдер…
Бераз тынлык.
– Монда торыйммыни?
– Ой, гафу ит, әйдә, зинһар, кер…

– Ә өегез якты. Миңа ошый…
(Мин оялып тора белмим шул.)
Шунда ялгыш сиңа карадым һәм
Әсир итте кабат карашың…
– Беләсеңме…
Ничек әйтим икән?..
– Мә, – дип чәчәк суздым, – бу сиңа...
...Минем йөрәк теге очрактан соң
Миңа түгел, сиңа буйсына...
Синең генә сулышыңны тоя,
Сине генә көтә көн һәм төн.
Әйе, көлерсең син, сабыр ит, дип,
Мин көтмәдем түгел, мин көттем...
Мин уйладым барсын...
Әмма уйлар
Бер ноктадан ерак китәлмый, –
Мин яратам бугай…

Әмма хәзер
Син «Кит!» дисәң,
Мизгел дә калмыйм.

Газаплама гына…

Синең яктан
Нинди җавап көтим микән мин?
Ни әйтерсең?
Ой, конфет та сиңа…
Ә син тып-тын дәштең:
– Мин белмим…

Шушы җавап өмет бирде миңа.
Һәм мин аның белән яшәдем.
Мин хушлашып чыгып киттем шундук.
Син дә миңа бер сүз дәшмәдең.

Ә соңыннан…
Мин яныңа килгәч:
– Бераз көтче, уйлыйм мин, – дидең.
Ә мин:
– Ул бит кире какмый! – диеп
И сөендем, ахмак, сөендем...

Күпме еллар узды шуннан соң, әй,
Син башканы таптың...

Мин дә һәм
Сүгендем дә ачы итеп кенә,
Бер чибәрне кочтым, алиһәм...
Менә шулай сиңа дигән сүзләр
Башкаларга мең кат әйтелде...
Башкаларны үптем ирененнән...
Әмма һаман нидер көтелде...

Ә тегесе, сине ташлап китеп,
Гел башканы бер кич озатты.
Һәм яңадан ачты минем өчен
Үзе бикләп куйган йозакны.

Гафу иттең...

Ул бераздан кабат
Берәү белән хата эшләде... –

Гафу иттең...

Ә мин, ә мин бары
Иренемне генә тешләдем...

Хәзер барсы башка, ул да ялгыз,
Син дә ялгыз,
Ялгыз мин дә.
Тик
Барысы да башка була алды!..
Инде кемгә генә ни әйтик?
Инде кемгә кирәк безнең серләр,
Кемгә кирәк безнең хыяллар?
Ямьле май киченнән еллар узып
Өрәңгеләр яфрак коялар... –
Сагышлы көз...

Инде шаукым узды,
Бөтен яраларны яматып,
Ә мин һаман көтәм,
Көтәм һаман
Әйтелмәгән теге җавапны.

**ОНЫТ**

Өметеңне яндыр утта –
Мин яныйм кайры булып...
Гафу үтенмим. Әмма син
Булдыра алсаң – оныт.

Оныт минем хыялларны,
Оныт минем сүзләрне.
Үзгәрүемне көттең син,
Сөен, Рүзәл үзгәрде...

Оныт мине, оныт гелгә –
Ертып ат күңелеңнән.
Син миннән көлгән күк, инде
Мин дә үземнән көләм.

Кем гаепле? Беркем түгел!..
Хуш, сине ятлар көтә.
Сүнде хис, шиңде чәчәкләр,
Тик тормыш... дәвам итә...

**БИЮ КӨЕ**

Бик таныш һәм ят җыр агыла.
Ашыкмый атладым яныңа.
Син ялгыз нигәдер,
Йөрәгең сизәдер –
Без бергә... Ә ялкын кабына...

Әйләнәбез без икәү биюдә
Агылган моңсу җыр көенә.
Син миңа карыйсың,
Мин сиңа карыймын.
...Бәхетле мизгелләр иде лә...

Мин сине яратып билеңнән кочамын,
Хыялый инде мин, күкләргә очамын.
Синең саф сулышың,
Ягымлы тавышың
Иркәли, мине син коч, җаным!

Әйләнәбез икәү тын биюдә
Агылган әкрен җыр көенә.
Син мине тоясың,
Мин сине тоямын.
Ә йөрәк сөенә, сөенә...

Мин читтә ялгыз идем, ләкин түзмәдем,
Күзләрең белән очрашты күзләрем.
Мин барын аңладым,
Тик соңга калганмын –
Кабатлый җыр соңгы сүзләрен.

Әйләнәбез икәү тын биюдә
Агылган моңсу җыр көенә.
Син – минсез, мин – синсез.
Ялгызым, сөюсез
Без менә – мин генә, син генә...

**КАРАҢГЫ ТӨННӘР АША**

Төннәр тыныч монда, һәм сине дә
Иркәлидер җилнең назлысы.
Тик кайгырма, зинһар: «Ул китте дә,
Үтте микән, – диеп, – барысы?..»
Син офыкка кара – күрәсеңме,
Соңгы нурлар сүнә, иртәгә
Иртүк кабат минем сөю булып
Сиңа җылы сәлам илтергә...

Мәхәббәтем, менә кабат җиһан
Кара-кара шәлен ябынды,
Менә кабат күкне ямьле бизәп,

Балкып меңмең йолдыз кабынды;
Кабынды ай, ап-ак нурын сибеп
Һәм яктыртып якын-тирәсен.
Ул соклана сиңа – соң кем каршы?
Күз тидерә генә күрмәсен...

Хөрмәм минем, сиңа моңсу мәллә?
Яшең түкмә юкка, аппагым.
Син онытма – безнең бер романлык
Хатирәләр, парлы ел барын.
Һәм юкка чыгару мөмкин түгел
Аларны һичкемгә, һичкайчан.
...Син көт мине – әнә минем маршрут,
Әнә автобусым, мин – кайтам...

*** * ***

Кимсенүне, ачу, әрнү хисен
Оныттырды ялкын көчлерәк.
Тамды тамчы, тамды саф яшь булып,
Эреде дә китте таш йөрәк.
Һәм яңадан рәхәт булып китте...
Хыялларның шашкан бер мәле!..
Киттең... Әмма, зинһар, җан җимешем,
Хушлашырга ашыкма әле.

Сулышыңны калдыр, вәгъдә итеп
Мизгелләрнең иң-иң татлысын.
...Һәм бары тик уйнама хис белән,
Ә калганы – миннән... барысы!..

## СӘЛАМ РҮЗӘЛДӘН

Исәнме, чибәр кыз, сөйлә,
Ничек хәлләрең?
Әйе, барысы да яхшы,
Әйе, беләмен...
Нигәдер күзләрең генә
Аска карыйлар...
Сине чакыралармыни?.. –
Бәй, алайса бар...
Тик сөрт ялган яшьләреңне
Талган күзләрдән...
Әй, чибәр кыз, оныткanмын –
Сәлам Рүзәлдән!..

Хәтерлисеңме барысын?
Хәтерлим мин дә...
Мәхәббәт, сөю, хыянәт...
Акланма әйдә... –
Кызыл иренең, алсу йөзең,
Кыска итәктән...
Нәрсә көтәсең, чибәр кыз? –
Трамваең киткән.
Әйе, син иреклe шәхес,
Бу синең хакың!..

Ә мин бит сине шулкадәр
Үлеп яраттым!..
Юк, ярама тимә минем –
Барсы төзәлгән...
Син сөйгән Рүзәл юк хәзер –
Рүзәл үзгәргән...

Сәлам Рүзәлдән...

*** * ***

Маңгаемнан сыйпама син,
Чәчләремне таратып.
Буйсындырдың да үзеңә,
Күзләреңә каратып,
Инде яшем түктерәсең, түзалмыйча әрнүгә.
Һәм иреннәрең урнына мине салкын җил үбә...

Шул булдымы кайнар итеп «Сөям!..»
дигән сүзләрең?
Миңа карап, син һәрвакыт башкаларны эзләдең...
Әйдә тукталыйк шушында, ауффидерзейн;
Бик теләп
Миңа өйрәткән сөюне башка бирәүгә өйрәт.

## СӘГАТЬ ӨЧ ИНДЕ

*(Бер кыз исеменнән)*

– Сәгать өч инде,
Ә синнән
Бернинди хәбәр килми...
Шуңадыр, бәлки, күңел дә
Сөенми бүген,
Көлми...
Ул боеккан,
Нык боеккан!
Моңсулана да елый...
Йөрәк кенә «Җебегән!» дип,
«Үзең дәш!» диеп дулый.
Ә мин...
Мин куркам нигәдер...
Син читләшерсең кебек.
Ялгызым тәрәз төбендә
Моңаям,
Яшем түгеп...
Әйтәләр дус кызлар:
«Таптың
Иблиснең дә иблисен...»

Юк!..
...Минем яшь – әрнүем түгел,
Кайнар сөю билгесе...

## ТЕЛИСЕҢМЕ?

Телисеңме,
Мин ап-ак кар булып
Җебер өчен кунам учыңа?
Тик син мине өреп тизрәк эрет –
Тилмерттереп кенә борчыма...

Телисеңме, йолдыз бүлэк итэм? –
Әмма күктэ йолдыз күренми...
Телисеңме?..

Нэрсэ булды сиңа,
Ник яшьлэрең
Энҗе булып аска тэгэри?..

*** * ***

Йолдызлар да юкка чыкты инде,
Һэм буш калды кара күк йөзе...
Бар хислэрне бэйлэп тоткан нык җеп
Бер тиюдэ генэ өзелде...

Димэк, хислэр ялган хислэр булган,
Ялган булган кебек барысы...
Нигэ эле яшьле күзлэреңне
Миңа шулай төбэп карыйсың?

Җанга рэхэт... Рэхэт кенэме соң? –
Берни, берни җанга тими дэ!..
Синең белэн араларны өзү –
Бүген ике-өч сүз кимендэ...

Әмма эле яратасы килэ,
Яратасы килэ, сөйгэнем!..
Шуңа күрэ син дэ ярат мине,
Шуңа күрэ бераз түз, яме...

## САЗ ЧӘЧӘГЕ

Мин сине очраттым –
Тормышым чэчэген,
Салкын көз таңында,
Син һаман кичэге...
Шул ук ят елмаю,
Шул ук яшь күзлэрдэ,
Шул ук саф мэхэббэт,
Һэм шул ук... түзэргэ...
Шул ук җан җылысы,
Шул ук моң һэм сагыш...
Һэм сөю ураткан
Шул ук тар чолганыш.

Саз чэчэге,
Син тартасың мине,
Саз чэчэге,
Мин карышмыйм инде...

Мин сине өзэргэ
Кыймыйча йөргэндэ,
Синдэ бары якын
Дустымны күргэндэ,
Юлларга аркылы
Син чыктың да үзең
Сазлыкта үскэн бу
Чэчэкне өздердең...
Мин сине яраттым,
Яратам да эле,

Тик упкын бу сөю,
Син сизмисең, әйеме?

Син бит саз чәчәге –
Үрелдем дә менә,
Әкренләп барабыз
Сазлыкның төбенә...
Никадәр вәгъдәләр
Һәм үтмәс вакытлар –
Бәхетле сәгатьләр,
Кадерле минутлар...
Сагыну, юксыну
Һәм тую барсыннан –
Сазлыкка бер адым
Басасы басылган, –
Сабырсыз кискенлек,
Сагышлы көрсенү
Бу сөю күк түгел,
Ләкин бу нәкъ сөю...

Саз чәчәге,
Сөешеп гомергә,
Саз чәчәге,
Без батабыз бергә...

**КИЧӘ**

Арадагы низагларны
Без ерып чыктык көчкә.
Һәммәсе дә шәп күк иде,
Әмма һәммәсе – кичә.

Нәфрәт мәхәббәткә түгел,
Сөю нәфрәткә күчә.
Кичә безгә рәхәт иде,
Тик рәхәт иде – кичә.

Мәхәббәт шундый хис шул ул,
Сөйгән күк буласың да,
Бөтен акыл күзәнәге
Тозсыз хискә буйсына.
Талпынасың, ашкынасың
Күбәләк кебек утка.
Яшь түгәсең ак мендәргә,
Газаплап җанны юкка.

Күздә томан – эйфория –
Барысы рәхәт сыман.
Йөрәк кенә... ярата да
Нәрсәнедер юксына...

Нәрсәдер җитми йөрәккә,
Җан ачынып сүгенә,
Һәм беркөн уза сөйгәнең
Исәнләшмичә генә.
Йөрисең ялгызың, әйтик,
Бер-береңне белмичә.
...Әйе, безгә рәхәт иде,

Тик рәхәт иде – кичә...

Кичә
Без бергә идек.
Кичә
«Яратам» дидек.
Кичә...

* * *

Минем хыялым булмадың шул син!
Бар өметем була алмадың...
Ак фәрештәм булып тоелдың да,
Эх, алдадың мине, алдадың...

Мин ниндидер нурлар күрдем синдә
Һәм ниндидер серле яктылык.
Иярдем мин, берни аңламыйча,
Нур-рәшәгә – сиңа тартылып...
Бу мәхәббәтмени? Белмим хәтта...
Түгелмени?.. Авыр соравы...
Барсы болай булмас кебек иде!
Барсын яхшылыкка юрадым!..

Акламадың барсын... Әмма сиңа
Гаеп тагар өчен юк хакым.
Син минеке булмадың да бугай,
Димәк, чит берәүне югалттым...

Әйдә таралышыйк без, булмаса,
Тилмертмик лә юкка йөрәкне...
– Ә мәхәббәт? – дисең... Җаным, миңа
Газап булган сөю кирәкми...

**СИН ИДЕҢ**

Җан авыртып, әрнегәндә күңел,
«Барсы узар әле, көт», – дидең.
Һәм бар дөнья мине онытканда,
Минем янда бары син идең...

Яшь тәгәрәп, битне чылатканда
«Юк, килешми, зинһар, сөрт!» – дидең.
Маңгаемнан үбеп юатучы
Минем янда һәрчак син идең...

Аерылганда, күзең күтәрмичә:
«Мин яратам сине бик!» – дидең.
Мин дә сөйдем, һәм ул сөйгән кешем,
Сизден микән... Бары син идең...

**ӨЧ ЙӨЗ ЧАКРЫМ**

Безнең араларда – өч йөз чакрым,
Таулар, кырлар, яңгыр яшьләре...
Җилләр нинди хәбәр китерсә дә,

Син барыбер мине көт, яме...

Монда чегән кызы язмыш сата,
Биш тәңкәгә сөйли барысын:
– Синең юлың сөйгәнеңнән читтә.
Мин үзем дә беләм анысын…

Безнең араларда киң урманнар,
Ак болытлар, чишмә, киң Идел.
Тик килмәстер диеп кул селтәмә,
Син барыбер һәрчак көт мине.

Монда карт карчыклар гайбәт сөйли,
Шуны отып ала барысы…
– Әллә кая йөрисең син, – диләр,
Мин үзем дә беләм анысын.

Безнең араларда ал шәфәкълар,
Офыклар һәм эңгер дә меңгер.
Тик өметең инде калмаса да,
Син көт, яме, мине барыбер!..

Юллар уңга-сулга җәелгәннәр,
Тотасы да берсен сайлыйсы…
– Сиңа әнә көнчыгышка таба...
Мин үзем дә беләм анысын...

Безнең араларда өч йөз чакрым,
Өч йөз чакрым – җанның сусавы.
Тик син көт. Мин, һичшиксез, кайтып
Күкрәгемә сине кысармын...

**ИСКЕ ФОТОРӘСЕМ**

Икәү төшкән иске фоторәсем.
Салкын кич һәм җылы кочаклар...
Шат елмаю бары, ә күзләрдә...
Ә күзләрдә – сүнмәс учаклар.

Тирә-юнь караңгы, күзләр генә
Ниндидер ак якты сирпиләр.
Вакыт кына нидер санап уза,
Вак мизгелләр генә үтмиләр.

Җан җылысы... Синең йөрәгеңнең
Үз җанымда сизгән тибеше...
Һәм элекке кебек читенсенү,
Һәм элекке фикер сөреше...

Сезнең капка төбе. Сезнең бакча.
Сезнең... һушны алыр сиреньнәр.
Кайнар сөю – салкын төн учында –
Балдан татлы кайнар иреннәр.

Кайнар хисләр... Башны әйләндергән
Мәңге чынга ашмас хыяллар...
Сезнең турга кадәр икебезне
Бу кичне дә илтеп куйганнар...

Оялчан ай керфек аша гына

Күзәтәдер кебек әле дә...
Иске уйлар... иске фоторәсем...
– Сау булып тор, җаным, әлегә...

Иске уйлар, иске фоторәсем –
Иске Рүзәл һәм син... Иске ямь...
Күз яшемне сөртеп, әкрен генә
Алып куйдым барсын өстәлдән.
*** * ***
Алай ук җитди карама,
Үтенәмен, кирәкми.
Беләмен, авыр шәхесмен,
Беләмен, таш йөрәк мин.

Тик күпме тирән сулама,
Үзгәрә алмамын бит.
Түзәсеңме, түзәрсеңме –
Анысын үзең хәл ит…

– Яратасыңмы? – дисеңме?
Ничек кенә анысы...
Тик мин аңлата алмыймын,
Ә син аңлый алмыйсың.

Булдырабыз әмма йөзне
Яшьләргә чылатырга.
Син миңа карата салкын,
Ә мин үз чиратымда

Сине күкләргә чөймимен,
Гөл бирмим кочак-кочак.
Әмма син ныграк сөясең,
Сиңа авыр булачак.

Мин дә көр түгел түгелен,
Әллә ни эшли йөрәк.
Синең сөюең Гётеча,
Теш сызлавы кебегрәк –

Авырта да һәм шунда ук,
Даруы басар диптер,
Тамырыннан йолкытып та
Атасы килми никтер.

**СИН ОНЫТМА МИНЕ**

Син онытма мине беркайчан да.
Һәм кем генә сине яратып,
Нәрсә генә вәгъдә итсә дә ул,
Юлларыңа гөлләр таратып,
Ирененнән үбеп, кочып-кочып:
– Мин яратам сине, – дисә дә,
Диңгез төпләреннән энҗе табып,
Муенсалар тезеп бирсә дә,
– Әйдә оҗмахларга юллар ачыйк,
Без моңарга лаек бит, – диеп,
Алларыңа алтын ыргытса да,
Син онытма мине…

Син онытма елга ярындагы

Без икебез яккан учакның
Очкыннарын чәчеп дөрләгәнен,
Дөрләгәнен һәм син кайчакны
Искә төшер минем сүзләремне…
Хәтта мин белмәгән кайсыдыр:
– Үткәннәрне әйдә онытыйк! – дип,
Иномаркаларга утыртып,
Бөтен дөнья буйлап йөртсә дә һәм
Ул булса мәңгелек җан тиңең,
Мин сөйгәннән артык яратса да,
Син онытма мине...

*** * ***

Әйдә болай... Син калдырып мине
Ычкынасың бөтен дүрт якка...
Белмим инде, әнкәң куенынамы
Йә дустыңа, бәлки, кунакка...

Һәм онытасың мәңгегә, гелгә,
Кайчан монда ниләр булганын...
Юкка чыгарасың хәтереңнән –
Бу бик җиңел нәрсә бит, җаным...

Күзләреңне генә бары йом да,
Тирән итеп сулыш ал да бер...
Һәм шул гына, бәгърем минем, безгә
Аерыласы инде барыбер.

Шуңа күрә вакыт сузмыйк, яме?
Кызгандырма түгеп яшеңне,
Йөрәгемә нәфрәт салма, зинһар,
Ул болай да тәмам өшеде.

Иркәләмә, үтеләсе этап
Югалтусыз гына үтелгән.
Ә хәзер кит... Җаның-тәнең белән
Күз алдымнан кит син!..
        Үтенәм...

## ЯҢА ЙӨРӘК

Матур, ак кояшлы
Ялтырап торган көн!
Йа Раббым, һәммәсен
Күрергә өйрәттең!
Никадәр гүзәллек,
Матурлык никадәр!
Йөрәгем, ни өчен
Тибәсең бу кадәр? –
Сабыр ит син бераз,
Ашыкма, ашкынма...
Һәммәсе бер көнлек,
Туктап ал чак кына...

Өр-яңа йөрәгем,
Соңладың син бераз –
Урамда кыш булып,
Күңелдә генә яз...
Урамда кар булып,

Күңелдә гөл үсә...
Тик узам барыбер
Берни дә күрмичә...
Өр-яңа йөрәгем,
Син туздың да бугай...
Яратам шикелле...
Тик буталмый алай.

Шатлыклы елмаю,
Бәхетле кыяфәт...
Чәчәкле тормышта
Чәчәксез киләчәк...
Чәч тузган җилләрдә,
Ә алда тар сукмак...
Һәммәсе томанлы,
Ләкин һәммәсе – ак.
Колакта ят тавыш,
Һәм күзләр йомылган,
Агачның бәсләре
Йөрәккә коелган...

Беркатлы мәхәббәт
Яшәргә өйрәтә...
Үзгәртә дөньяны,
Язмышны үзгәртә...
Ләкин кан басымы
Бүген кабат түбән...
Тормышның йомгагы
Сүтелеп бетелгән...
Ә йөрәк әле яшь,
Ә йөрәк – өр-яңа!
Һәм иске хисләре
Кирәк түгел аңа...

*** * ***

Ишетәсеңме, урамда
Ят тавышлар – җил сызлый.
Урам – буш, минем тупсадан
Бер атна беркем узмый.
Тамчылап яңгыр сибәли,
Тамчылап уза сәгать...
Хатың килеп җитмәде, тик
Язгансың икән – рәхмәт...
Телефон «үлгән», ахрысы:
Эндәшми, тавыш бирми.
Кемнәрнедер көтә-көтә,
Бирелгән вакыт кими...
Караңгы бүлмә һәм бары
Йолдыз җемелди күктә.
Тамчылап яңгыр сибәли,
Тамчылап сәгать үтә...
Кайдадыр ишек ябылыр
Һәм бикләп куяр төнне...
Исәнме, матурым, мин бу,
Кил яныма, коч мине...

## III бүлек

***Югала кояш нурында***
***Йә яралый канатын –***
***Хыялым...***
***...мин аны җаннан***
***Кубарып күккә аттым...***

**КЫШКЫ ҖЫР**

Ак болытлар йөзә көнбатышка.
Һәм кемнедер көтә урамнар.
Шәһәремә минем ак кыш килде,
Аның белән карлы-бураннар.

Җыр үзгәрде, кошларының моңын
Алыштыра җилнең сызлавы.
Ә урамда әле ак кар ява,
Ә урамда каты бозлавык.

Һәм радио сөйли: иртәгәсен
Җылытырга тиеш, дип. Тик хак –
Ак кар ява, җемелди ал кояш,
Һәм һәрвакыт шулай булачак.

Мин үлчәүдә яшим бу фасылда
Һәм озатам көз-яз арасын.
Алга карап, әмма сайламыйча
Кай юллардан күпме барасын.

Мин сукмактан атлыйм, сулышымны
Өреп бияләйсез йодрыкка.
Ак кар ява… әйтелмәгән сүз күк,
Җырланмаган җыр күк – ап-ак кар…

*** * ***

«Урамда бик салкын!»
Районның бар халкын
Кисәтә «Кукмара авазы».
Тәрәздә бизәкләр,
Гыйнварны әләкләп,
Авыллар сагыналар язны.

Суыра төтенне
Биеккә күк йөзе,
Юлларда җемелди ап-ак кар.
Елгалар өстендә
Боз шул су төсендә.
Һәм авыр көрсенә елгалар.

Еракта-еракта
Ят кояш. Мин кайтам
Бураннар һәм җилләр аркылы...
Минем үз дөньяма,
Җылысын тоярга
Кадерле Кукмарам халкының...

*** * ***

Тын почмакта никтер тынмый йөрәк.
Нәрсә борчый аны бу төндә?
Кара күктә мең йолдызлар булып,
Ник бер йолдыз күңел күгендә...

Машиналар төнне ертып уза.
Җил ашыга алар артыннан.
Кичә генә дулап йөри идем,
Бүген инде соңгы үч тына.

Барсы яхшы, тыныч һәм яз килә.
Тик үзгәртү нидер икеле.
...Тамчы гына ап-ак карга түгел,
Ә йөрәккә тама шикелле!..

**САГЫШ**

Кояшның нурлары ак карда чагыла,
Ниндидер сәер хис кагыла җаныма.
Ә кояш елмая, һәм зәңгәр күгендә
Нурларын югалтып, офыкка күмелә.

Зирекләр шаулаша тар инеш ярында,
Челтерәп саф чишмә күзәтә барын да.
Зиреккә бәс кунган, шул ук бәс чәчләрдә,
Ә минем нигәдер күзләрем яшьләнә...

Никадәр иркен кыр! Һәм текә таулары...
Нәрсәләр белән мин дәвалыйм ярамны?
Кемдер нидер дәшә, ә миңа китәсе,
Һәм соңгы мизгелдә югала һәммәсе...

**БУРАНДА**

Ак кар эреп, агып төшә биттән,
Ачу тулы ачы яшь кебек.
Юл күренми, һәм күренми офык,
Җил кар ата йөзгә, төкереп.

Тын тукталыш. Көздә килгән булсак,
Озата кыш инде зур юлга.
Каткан куллар иңнән карны коя.
Сәгать ике... Сәгать өч тула...

Көн авыша кичкә, туң туфрактан
Атлый берни тоймас аяклар.
Кояш сүнде, аның белән – өмет,
Без туңабыз иман кабатлап.

Ә йортларда дөрләп мичләр яна,
Һәм парлана рамда пыяла!
Тышта – салкын, җил изүне чишә,
Кояш баткан якка куалап...

**ГАФУ ИТ, ӘНИЕМ**

Гафу ит, әнием, каралган җан өчен,
Гафу ит, әнием, каргалган җан өчен.
Инде күз алдымда калмагач киләчәк,
Гафу ит, әнием! Кемдер тик көләчәк...
Кемдер бер кызганыр мәгънәсез улыңны,

Кемдер, бәлки, эзләр узган тар юлымны,
Кемдер берни әйтмәс, тик, кысып баш миен,
Югалыр, әмма син гафу ит, әнием!
Коелган яшь өчен, тапмыйча үз көчен,
Сагышлы йөзеңдә җыелган сыр өчен,
Гафу ит, әнием! Гафу ит, гафу ит!..
Бәлки, соңдыр барсы – мин аңламадым бит!
Мин аңламадым бит тормышның мәгънәсен,
Мин аңламадым бит – син яхшы беләсең!..
Йөрәктә – сәер хис, яшь акмый күзләрдән,
Мин сөйлим, тик минем әйтелгән сүзләрдән,
Бәлки, кемдер ярсыр, башкалар бер көләр,
Бәлки, кемдер сүгеп бер ачы сүгенер,
Бәлки, кемдер аңлар һәм керер хәлемә.
Көч җитеп әйтәсен мин әйттем дә менә...
Уч белән яшереп җанымның ярасын,
Инде белмим, хәзер кайларга барасы?
Чөнки күз алдымда киләчәк юк минем,
Ләкин бар үтенеч – гафу ит... әнием...

**ТАМЫРЛАР**

Күз алдында – пәрдә, аның аша
Тонык кына кояш ялтырый.
Тышта җылы, бары куллар гына
Әллә нигә туңа һәм ойый...
Түзалмады ярты көнгә яңгыр...
Түзалмады өч-дүрт сәгатькә...
– Китәм, – дисең. Ә мин калам әле,
Син үзеңә мине ияртмә...

Урман саклый әле һәммәсеннән,
Текә ярлар гына ишелә...
Яшел таулар, яшел таллар кала!
Болар барсы татлы төш кенә...
Су эчмисең, иеләсе диеп,
Күпме еллар аккан чишмәдән...
Барсы кала – йә без картайганбыз,
Йә барысы бераз яшәргән...

Бу чирәмдә без, эх, ауный идек,
Бу таулардан аска йөгереп,
Бар җилләрнең якасыннан тотып,
Төшеп җитә идек иң элек...
Зират шаулый... Кабер саны арта,
Кими, димәк, безнең чордашлар...
Каберләргә түгел, күңелләргә,
Йөрәкләргә баса бу ташлар!

Монда басма иде – хәзер ул юк,
Монда чишмә иде – күмелгән...
Әле генә тулы калган чиләк
Җирдә ауный, суы – түгелгән...
Бил тиңентен печән – бирче чалгы,
Чабыйм әле тиргә манчылып!..
Дәшүче юк, беркем дә юк янда,
Яра гына әрни ачылып.
Барсы үткән. Елга гына ага,
Текә ярлар гына ишелә...

Әйтерсең лә монда узган гомерем
Кичә ятып күргән төш кенә...

Су эчмисең, иеләсе диеп,
Кочып эчеп үскән чишмәдән...
Чәчләр генә бераз агарганнар,
Күзләр генә бераз яшьләнгән...

– Китәм, – дисең... Миңа да китәсе...
Тик үзеңә мине ияртмә...
Бераз торыйм. Түзалмады йөрәк
Ярты көнгә, өч-дүрт сәгатькә...

...Нәни чакта моннан узган вакыт
Мәңгелеккә диеп узганбыз...
Яз яшәртә, бер без генә инде
Бүгенгедән яшьрәк булмабыз...

**КАРАҢГЫЛАНДЫ**

Караңгыланды. Янды
Кичке шәфәкъ һәм
Кубарды
Карны
Ак рамнан.
Арды,
Көн күптән арды.
Ярды
Яктыны,
Карны,
Ашкынды югары...
Бары...
Узды урамнан.

Караңгыланды. Янды
Якты йолдызлар.
Ауды,
Ауды нур.
Яуды кар.
Ут сүнде –
Күмде
Кар акка.
Ә шәм кыланды,
Уйнады,
Ул – янды.
Һәм шик калмады,
Югалды:
Вакыт китәргә,
Моннан китәргә,
Туган җиремә,
Туган туфракка –
Еракка...

**ИРЕКЛЕ МИН**

Богаулар кубып төштеләр һәм җимерелде читлек.
Кемдер миңа кулын сузып тын пышылдады:
«Киттек».
Кая? Нигә? Минем өчен ансы барыбер, ләкин

Күкрәк тутырып мин монда соңгы сүземне әйтим:

– Ирекле мин! Ирекле мин! Кошлар кебек ирекле!
Мине язмыш һәммәсеннән мәңгегә азат итте.
Ирекле мин! Бу саф һава исертә мине һәм мин –
Бу таушалган туфрак, моннан тизрәк
китәргә телим!

Ләкин кая китим? Мине кем көтә һәм кем көтте?
Беркем түгел. Берьялгызмын, күп көнем
монда үтте.
Миңа кояш таң китерде, һәм чык китерде
шул таң,
Мин каршы килә алмадым – мин тормышны
яратам!..

– Ирекле мин! Ирекле мин! Кошлар кебек ирекле!
Мине язмыш бүген менә барсыннан азат итте.
Барсыннан мәхрүм итте… Мин – ирекле, мин –
хөр, азат!
Кулларда богаулар тоймау – бу минем иң зур
җәзам…

Мине бу кошлар сагыныр, һәм елар шиңгән
чәчәк.
Мин җирне кочып елармын, ә ул бары көләчәк.
Кемдер миңа кулын суза: «Киттекме?» –
«Әйе, киттек…»
Сыпылды минем богаулар, ишелде
минем читлек.

– Ирекле мин! Ирекле мин! Кошлар кебек ирекле!
Мине язмыш һәммәсеннән мәңгегә азат итте.
Ирекле мин! Мин – азат һәм дүрт ягым кыйбла
минем.
Күкләр! Сезнең каршыгызда соңгы тапкыр иелдем!..

**«ЗЕНИТ» – «РУБИН»**

Ал майкалар тәндә күптән.
Казан көтә һәм мин көтәм.
Сәгатьләрдә – биш минутсыз алты.
Йөрәк ярсып тибә – сизмим.
Алда уен: «Зенит» – «Рубин».
Баш хөкемдар тупны өскә атты.

Артка адым һәм нык һөҗүм.
Максат өчен! Җиңү өчен!
Үзышаныч – монда иң зур корал.
Унҗиденче алга үтә,
Пас! Әмма туп читкә китә...
Пас! Капкада туп, кара, тәүге гол!..

«Зенит» тибә, һәм туп өстән
Безнең күкне ярып үтә.
Аяк чалу – күрде микән судья?!!
Алга адым, «Зенит» ярып,
Сакчыларның уза барын.
Хата! Һәм Петербург яшен коя...

Алга адым һәм нык һөҗүм.
Казан өчен! Җиңү өчен!
Арбитрның тынды сызгыруы...
Йөрәк ярсып тибә – сизмим.
Исәп 0:1 «Зенит» – «Рубин».
Мизгелләрнең әле иң кызуы...

**ТУГАН АВЫЛ**

Ашыкмый атлап төшкәндә
Көньякка Шөн тавыннан,
Күренә ул – тау астында
Олы авыл салынган.

Монда чишмәләр чылтырый
Җыр кебек – шаулый, тына...
Монда төн яп-якты.
Ә ай
        төнге җилдә атына.
Кичке күктә йолдыз яна,
Җем-җем килә нурлары;
Текә ярларга бәрәләр
Нократның дулкыннары;
Монда әле хаклык өстен,
Һәм юк фальшь,
Һәм юк ялган,
Мондагы хыяллар әле
Нәҗескә буялмаган!..
Монда әле җиле дә җил,
Һәм печәне дә печән.
Монда әле кирәк-ярак
Кулдан-кулларга күчә...

Монда минем җан ирекле,
Кызурак тибә йөрәк.
Ләззәт белән сулар өчен,
Миңа шул һава кирәк!..
Миңа кирәк шул халкымның
Ярдәме, рухы, көче...
Киртәләрне узып,
Кабат
Киртәгә җитәр өчен.
Миңа кирәк бу елганың
Тынсыз, көчле агымы...

Мин яңадан кайттым бире –
Авылым, таныдыңмы?

**ЧИЯ АГАЧЫ**

Мин бәләкәй чакта бабам белән
Утыртылган чия агачы
Корыган быел.
«Нәрсә шуннан, – диләр, –
Ярый корыды, чабып алганчы.
Җимешләрен кабу мөмкин түгел,

Йөз зәхмәтнең сиксән ачысы,
Кояш нурын каплап үскән куак –
Гүзәллекнең кара тамчысы…
Үзе озын, үзе чәнечкеле,
Тәнне ерта, сузсаң кулыңны».
Һай,ерактан алып кайткан идек,
Узып сукаланган болынны...
Быел инде...
Пешмәс ал чияләр,
Ботаклары җиргә сыгылып;
Кошлар кунмас таңны каршыларга,
Мин моңланмам яшькә буылып;
Тәгәрәмәс яшел чирәм буйлап
Иртә купкан сары яфраклар.
Чияләрне юган чык тамчысы
Инде таммас кара туфракка!
Тик... таң атар, офык алсуланып,
Тәүге жилләр кабат исәрләр.
Үсентеләр, кабат башын чөеп,
Һәр көн саен җырлап үсәрләр.
Кояш кабат нурга күмәр барсын,
Җылы сулыш белән иркәләп.
Җәйге яңгыр кабат качар читкә,
Әллә нәкъ кояшка үпкәләп?..
Һәр яз саен бөтен карлар эреп,
Кабат гүзәлләнер Җир шары.
Болар кабат килер һәммәсе дә!
Бөтен үткәннәрне кубарып…
Календарьның очар ак битләре
Сагындырып үткән һәр көнне.
...Бабам үлде, мин дә сулырмынмы,
Быел корган чиям шикелле?..

## КАРЛЫ ЯҢГЫР

Карлы яңгыр елап-дулап бүген
Тәрәзәнең рамын чылата...
Яшел чирәмнәрне җиргә сылый,
Агачларны бөгә, елата...

Кара болыт, каплап авыл күген,
Бар дөньяны баскан моңсулык.
Күңелләргә чиертеп әрнетәме? –
Карлы яңгыр ява яшь булып...

Карлы яңгыр ява... Кем уйлана,
Кем кайгыра һәм ни хакында?
...Инде күптән ялгыз калган таган
Тынсыз җилдә моңсу атына...

## ЯЗ ИДЕ

*Тормышның кадерен белмибез без, кешегә һаман да нидер җитми – булган саен артыграк кирәк аңа. Явыз ул кеше... Кемнедер нидер канәгатьләндерми, кемгәдер нидер ошамый, ә нәтиҗәдә барысы өчен дә безгә түлисе. Ләкин нигә без соң әле, нигә кемнеңдер хаталарын без каныбыз белән юып төшерергә тиеш?.. Кем җавап бирер моңа? Беркем дәшми...*

*Еллар узар, бу сугышның инде нидән башланганлыгын гына түгел, ә гомумән, аның булганлыгын да искә алмаслар. Һәм кирәкми дә...*

Ул көн таң атмады –
Мылтыклар какшады,
Тик кургаш йөрәктә эреде.
Кояшны куалап,
Тән йөрде саз ялап.
Офыкта канатлар күренде.
Яз иде, сандугач
Сайраган карт агач
Корыды баткаклык эчендә.
Ярканат онытты
Ярырга болытны
Һәм ауды козгыннар күченә.
Без калдык, ә янда
Нәкъ кыргый хайвандай
Калды ач дошманнар өере.
– Бу, – диләр, – соң сугыш,
Автомат ләкин буш,
Бу безнең хыяллар идеме?

Кыйналган табигать,
Кыйналган, ярдәмсез!
Югалган бу дөнья,
Югалган хәбәрсез.
Буялган Җир шары,
Кызылга буялган!
Югалган бу дөнья,
Мәңгегә югалган…

Ул көн җил соң чыкты,
Кубарып балчыкны
Очырды еракка-еракка.
Һәм безнең төркемнән
Белмәде беркем дә
Үлемен көтәргә кай яктан.
Кинәт кабат ак ут,
Дәште кемдер: «Капут!» –
Һәм кайнар тимере – маңгайда.
Егылды артына,
Йөрәге тартыла:
Юк булды әле яшь малай да.
Җир аска убылды,
Җиргә кан коелды,
Уйнады тәнендә саф яңгыр.
Бу безнең язмышмы,
Һәм Ходаймы кушты?
Һәм каберме безнең шушы кыр?

Кыйналган табигать,
Кыйналган. Ярдәмсез!
Югалган бу дөнья,
Югалган хәбәрсез.
Буялган Җир шары,
Кызылга буялган!
Югалган бу дөнья,
Мәңгегә югалган…

Ул көн таң атмады –
Җил тик кабатлады
Язмышның вакытсыз әмерен:

«Яшәгез, – диде ул, –
Килгәнче зур давыл,
Татымый тынычлык кадерен!»
Ә яңгыр сикерде,
Уйнады, тәкерде,
Биеде янган танк өстендә.
Безнең күз алдында
Учаклар кабына,
Һәм соңгы өметләр сүрелә.
Хәзер кайдадыр таң
Кызарып бер ата,
Хәзер кайдадыр кемдер бик шат.
Хәзер кабат чаткы,
Соң патрон күк атып,
Туфракка иелербез кабат.

Кыйналган табигать,
Кыйналган. Ярдәмсез!
Югалган бу дөнья,
Югалган хәбәрсез.
Буялган Җир шары,
Кызылга буялган!
Югалган бу дөнья,
Мәңгегә югалган…

**ХЫЯЛЫМ**

Канатын җәйгән як-якка,
Ашкынып оча һаман.
Кулымны селкеп аңарга,
Артыннан карап калам.

Өскә менә, аска төшә,
Кабат талпына соңрак.
Кемгәдер нәрсәдер дәшеп,
Кемнәндер нидер сорап.

Югала кояш нурында
Йә яралый канатын –
Хыялым...

...мин аны җаннан
Кубарып күккә аттым...

**ЗИРАТТА**

Әллә яңгыр ява инде...
Салкын.
Үзәкләргә кадәр үтмәле...
Зират. Тынлык.
Килдем менә... Гәрчә
Монда мине беркем көтмәде.

Күпме кабер аяк асларында...
Күпме ташлар кабер өстендә.
Бусы – сабый...

Монысы да икән...
Фоторәсемнәргә төс кергән...
Бусы – картым минем...
Аның белән
Хушлашу та җүнләп булмады.
Ә үлеме гади...
Ә үлеме
Өч хәрефтән тора нибары...

Бусы – күрше. Яхшы абзый иде.
Уйламыйча ничек качасын,
Без еш керә идек аңа кичен
Таларга дип алма бакчасын...

Бәй, бу апа...
Ул да үлгәнмени?..
Шулай баскан җаны алҗуын...
Нәрсә дим соң инде? –
Иннә лиләйһи
Вә иннә иләйһи раҗигун...

Күпме кабер икән...
Күпме кеше
Соң куышын тапкан биредә...
Күпме шәхес монда!..
Тик арадан
Тавыш бирәм бары мин генә...

Монда башка тормыш.
Монда тыныч.
Җиле генә сыйпый йөземнән...
Кабер арты кабер.
Дисбе кебек.
Тик дисбесе генә... өзелгән...

## СОҢГЫ ЮЛГА

Бисмилләһир-рахмәәниир-рахиим
Г...А...Г... улы
12.12.2006 үлгән

*Кабер ташы язмасы*

Буран дулый.
Әллә нинди бу көн.
Яме дә юк, качкан кояшы.
Һәм кемнедер
Һаман
Көткән кебек,
Җемелди... кабер ташы...
Тау.
Биек тау урап алган
Ят, кечкенә авылны.
Ай-һай авыр була кайчак табу
Кышкы буранда юлны. –
Әйтерсең лә
Шушы авыл
Качарга тели Хактан.
Тик язмыштан качып булмый –
Бу хата,

Олы хата.
Сызгыра җил,
Кар бөртеген
Кубарып җиргә сылый.
Нигә тынгысызлана җил? –
Җил яңа корбан сорый...

...Алар – икәү.
Яши бу авылның
Үзәгендә,
Инеш янында.

...Шифер түбә
Кабат сыкрап-сыкрап,
Кышның авыр карын ябына.
Бу авылда
Ак кар ак сөт кебек
Ап-ак була –
Күзләр камаша.
Һәм тын гына карый
    ап-ак ае...
Зәңгәр болытлар аша.
Төн тын монда.
Кичен ишетелми
Машинаның
    зәһәр тавышы...
Таң атканчы
Авыр сулый бары
Иске төпнең олы куышы.
Чемер-чемер килә
    йолдызлары.
Әйтерсең лә өши, туңалар;
Төннәр буе бер-бер
Атылышып,
Иблис илчеләрен куалар...

Бу йорт ялгыз, –
Кичен, бик соң гына
Сүнә монда электр яктысы;
Ул иртәнең тәүге таң нурларын
Инде күптән көтми, ахрысы...

Алар – икәү.
Берсе – ата, берсе –
Шул атаның корыч ярдәме.
Ишетелә бары шул ишектән:
– Улың кайда?
Улың өйдәме?
– Өйдә түгел...

Әллә кайчан инде
Шундый каты итеп чирләде...
Бар даруны йотты бугай үзе,
Тик файдасын гына
Күрмәде.
Ә хәзер ул читтә –
Дәвалана.
Процедура, осмотр, уколлар...
Эх, кайчан соң язмыш язганнары
Аны кире алып кайтырлар?..

Шыгыр-шыгыр ишек.
Буран уйный.
Җил умыра карны буранда...
Һәй, ул бәламе соң – тышта буран,
Өеңдә газ миче булганда.

Баганада инде утлар яна,
Ераклатып йолдыз нурларын...
Һәм төн тып-тын кабат
бер
йортының
Якты җемелдәвен
урлады.

Авыл йоклый.
Ай шәүләсе
Юкка чыкты берзаман...
Һәм бар дөньяга таралып,
Яңгырады соңгы азан:

– Ләә иләһә ил-аллаһу...

Бетте.
Йомылды күзләр...
Җил генә тынгысызлана,
Җил генә җанны өзә... –
дулый һаман...

Нәрсә белән икән
Ул килешми декабрь кичендә? –
Сабый булып елый да
Үкерә –
Чыдый алмый булган көченә...

Ни дип әйтим тагын? –
Төн җитте,
ай
Болытларны ертып калыкты.
Һәм тын гына
юрган атып, Аллаһ
Тәмле төшкә кертте халыкны...

Кичке тынлык
кайчак,
әкрен генә
Сәгать сугуыннан өзелеп,
Акты чиксез елга кебек шаулап,
Һәр тамчысын җанда сиздереп...

Сәгать сукты:
Берне,
Өчне,
Дүртне...
Һәм кызарды ерак офыкта.

...Вакыт, син әйт: кая чабасың соң?
Бер мизгелгә генә көт, тукта...

Туктамый шул...
Уйлап бирми хәтта –
Үз кулында сәгать кырлары!
Һәм яңадан

Алсу иртә җитеп,
Тиште күкне кояш нурлары...

Тик җил генә риза түгел кебек –
Һәр минутта җирне күзләде;
Ул тын гына
	күмеп китте
Йортның
Хуҗасының
	соңгы эзләрен...

Яуган карлар шыгыр-шыгыр аста.
«Иртәрәк шул», – ди кемдер читтә...
Буран гына, өзеп баш киемен,
Һаман
Кемнедер
Көтә... –
	улынмы?

Карт юк бүген...
Юк, ул карт түгел иде...
Ул яшәсә,
Яшәр иде күкне күкрәтеп!
Ә хәзер йә көчсез ята,
Ялгыз...

Инде кабер – әзер,
Инде такта – янда,
Инде казылган ләхет...

Әллә җил кытыклый шунда:
Ак карга яшь коела…
Соңгы тапкыр,
Соңгы җилләр
Озата соңгы юлга...

**БУ – МИНЕМ ҖЫР**

Бу туфрак минеке! Мин дә
Монда калырга тиеш.
Күктә кояш – сары алтын,
Ак чишмә – тере көмеш.

Бу агачлар – минекеләр,
Бу болын – минем болын.
Бу елга – минем елгам, һәм
Бу авыл – минем Толлым.

Зәңгәр һава – түбәм минем.
Яшел җир – минем идән.
Минем гөлләр шаулашалар
Тын искән язгы җилдә.

Бу кошлар моңы – минем җыр.
Ялкын – җаным янганы.
Яңгыры – күз яшьләремнең
Тып-тып җиргә тамганы.

* * *

Әкрен генә атлап килә егет,
Күккә аша мең-мең уйлары.
Муенында балкый ярым ае –
Сибә, җыеп, кояш нурларын.

Яннан узды бер кыз, бүген анның
Техникумда тәүге дәресе.
Учын кыскан, үзе тын пышылдый,
Ә учында – көмеш тәресе...

* * *

*(Блок буенча)*

Китап, дәфтәр, ачык тәрәз...
Мәнсез яуган йомшак кар.
Исеп, җилләр агачларның
Бәсләрен кубаралар.

Елый дөнья... Болыт кына
Каралтып уза күкне.
Кабат суык бер җебегән
Елганы үбеп китте.

Нишлисең, үлеп терелгәч
Кабатланыр һәммәсе:
Шул ук китап...
Шул ук йортның
Ябылмас тәрәзәсе...

* * *

Кабат айлы төн җитте дә,
Йокыга талды урам.
Җил агачларны борчымый,
Дуламый кубып буран;
Ай гына яна.
Һәм – рәхәт...
Тынгысыз дөнья – тып-тын.
Утлар сүнеп, төн авылны
Бөтенләй килеш йотты...
Йолдызлар коела карга:
Берешәр дә икешәр...

Табигать минем колакка
Пышылдый:
– Тәмле төшләр...

## ГРОЗНЫЙ

*Чечен тәмугын узган*
*егетләргә багышлыйм*

Сыпылган пыялаларда
һәр иртә уйный нурлар.
Томаннан ертып ала да
шәрә кала урамнар.
Ишелеп төшкән йортларның

юлда ята ташлары.
Кабат иртә, кабат кояш
өскә менә башлады.
Кабат яктыра һәм кабат
ачыла шәһәр күге.
Бу сәгатьләр, бәлки инде,
соң мизгелләрдер бүген...
Грозный! Нәрсә кирәк сиңа,
син бездән ни көтәсең?
Әмер гади – мылтык тотып
үрә катып үләсе...
Грозный! Каргалган башкала,
синдә мең аяк эзе,
Синдә булмаячак картлык,
синдә тик яшьлек йөзе...

**ҖИЛ УМЫРА ЧИТКӘ МИНЕ**

Барысы да күптән инде югалган безнең юлдан.
Яфраклар, күптән корышып, инде юлга коелган.

Күптән кар инде туфракны акка күмеп ташлаган.
Тәрәзәләр җылы көтми – чәрдәкләнә башлаган...

Өмет итмим – көннәр үтми,
календарь калган катып.
Җил умыра читкә мине – димәк, китәргә вакыт.

*** * ***

Нинди дөнья... Нинди заман җитте.
Нинди көннәр, нинди уйдырма...
Авыр бит, Раббым, бик авыр бит, ә, –
Син ялгызым мине калдырма.

Нинди язмыш, нинди җилләр исә,
Нинди сәер, сихри мизгелләр...
Бары моңсу гына карап тора
Ялгыз чагылышым көзгедән...

Нинди хыял, нинди өмет уты,
Нинди каргыш барсы астында.
Аһ, йөрәгем, нәрсә булды сиңа,
Тынычланчы, җитәр, ярсыма...

Нинди тормыш инде, болай булгач,
Җан җылысын каян табасы?..
Әле озак барасы, бик озак,
Әмма кая таба барасы?..

Арыдым, Раббым...
Авыр тормыш итү,
Инде нигә өмет итәсе?
Күпме көттем, күпме көттем, Раббым!
Тагын, тагын нәрсә көтәсе? –

Азат итче мине һәммәсеннән,

Алып ат бу авыр йөгемне...
Мин никадәр тартып барам аны –
Инде бераз җитәр түгелме?..

Хәл калмады...
Соңгы көчне җыеп
Кычкырасы килә калага...
Әмма барсы кайтавазым булып
Миңа кире кайта яңадан...

Онытасы иде барысын да,
Югалтасы иде булганын...
Без бу җирдә бары кунак кына,
Һәм мин дә шул – туфрак кунагы...

Һәм шул туфрак кире дәшә мине,
Ә бит әле бик аз яшәдем!
Сугып китте язмыш –
дәшми тордым,
Аяк чалды – кабат дәшмәдем.

Күпме җегәр кирәк җиңәр өчен,
Җыяр өчен барсын бер учка? –
Язмыш миңа гомер тәкъдим итте,
Һәм мин алдым аны бурычка...

Хәзер яшим менә нидер көтеп,
Нидер өмет итеп каяндыр.
Бәлки, әле генә узган көннәр
Инде үзе тормыш булгандыр?..
Бәлки, болар барсы бер төш кенә,
Һәм төш күреп ятамдыр, бәлки,
Күз алдыннан узган һәммәсе дә –
Шул төшемдә мизгел гүяки...

Йа Раббым, мин
арыдым әле бераз.
Бер ял итеп алмый булмас та,
Ятып торыйм әле хәл кергәнче,
Нәкъ хәзер үк менә, яраса...

Ярыйдыр бит?.. Яшел чирәм,
күктә
Ак болытлар йөзә тын гына.
Чишмә ага...
Ә йөрәккә авыр,
Һәм бугазга нидер тыгыла...

Тынгысызлыкмы соң? Ачу микән?..
Әллә тагын?.. Аңлый алмыймын.
Мин әз генә йоклап алыйм, яме,
Нәкъ шушында менә, ярыймы…

Ярый…
Рәхмәт…
Булды, башка сүз юк,
Ә син нәрсә әйтеп каласың? –
Барасымы? Әйе, барасы шул,
Әмма кая таба барасы?

Юллар бикле… Артта, алда да – бик,

Төгәлләнеп килә һәммәсе…
Һәм кайсыдыр кулын иңгә куя:
Ял итеп ал бераз, янәсе...

* * *

Ярым адым атлап кына
Ашыгабыз каядыр.
Барсы шул ук, барысы да
Әлеге дә баягы...

Сизелмәгән сөю хисе,
Онытылмаган сәфәр...
Озатып калган шәһәр дә
Кабул итмәгән шәһәр...

Күпме чакрымнар һәм бары
Бер елга сыйган хәтер.
Әллә ни булмады да бит,
Сагындыра нишләптер...

Кысыла йөрәк, сулышны
Чыгарса, ала белми...
Нигәдер бик борчыла, һәм...
Һәм... һәм... туктарга тели.

Ай бу хис җанны әрнетә,
Ай бу хис нинди таныш!..
Төзәлеп килгән ярама
Кагылып киттем ялгыш...

* * *

Ярты сәгать... Ярты сәгать тагын...
Һәм һәммәсе шундук тукталып,
Бөтен дөнья кубыр да төбеннән,
Бөтен дөнья тагын буталыр...

Вакыт... вакыт... Түземсезлек җанда,
Түземлелек җитми йөрәккә...
Ярты сәгать... Ярты сәгать калды!
Ярты сәгать түзү кирәк лә...
Түзеп булмас әмма...
        булмастыр шул...
Озак вакыт түгел, бар ансы –
Бер сәгатьлек кеше гомеренең
Ике ярты сәгать арасы...

* * *

Ни хәлләрең, туган җирем минем,
Ни хәлләрең, минем Кукмарам?
Поезд чаба, әмма минем өчен
Бу тукталыш соңгы, мин – калам.

Яңгыр, яума, йөрәгемә чиртеп,
Яңгыр, яума, зинһар, туктап тор.
...Артымнан җил йөгерә, бәлки, ул да
Минем кебек өйгә кайтадыр...

Таныш урам. Яңа тормыш. Монда
Барсы ага тыныч инештәй.

Әкрен генә сибеп үтте яңгыр,
Күз асларын гына юешләп.

Көзге җилләр яфракларын коя
Ак каенның асфальт юлларга.
...Тып-тын гына атлап кайтып киләм
Мине танымаган урамнан.
* * *

Хуш, Казаным! Синең чикләреңдә
Мин бер көн дә түзә алмамын...
Синең томаннарың буа мине,
Кирәк микән сөйләү калганын?..
Соңгы дәфтәр битен очкыч итеп
Очырасы иде җилләргә...
Кул селкиләр гади итеп кенә,
«Ияләнәсең ул», – диләр дә...

Хуш, Казаным!..
 Синең чикләреңдә
Мин бер көн дә түзә алмадым.
Син күз алдыңа да китермисең
Йөрәгемнең ничек янганын...
Син ваемсыз...
Аңламыйсың минем
Нигә шулай тузгып азганым,
Һәм буасың мине, син буасың!
Хуш, Казаным,
Минем Казаным...

* * *

Озатырга чыкма арттан, әнкәй,
Күз яшьләрең авыр җаныма...
Тәрәзәдән генә кулың изәп
Карап кал, тик озак багып торма –
Син һәрвакыт минем янымда!

Мин озакка китмим, әнкәй, ышан!
Сагынсаң да, авыр сагынма...
Өстәл артларында йомшак көлеп,
Яннарымда басып торган кебек,
Син һәрвакыт минем җанымда!..

**ФОНТАН**

Эссе.
Һава җитми.
Кайнар сулыш,
Тынны кысып, тышка агыла...
Һәм мин карыйм,
һәм мин алга барам –
Сатлык шәүләм арттан тагыла...

Фонтан бәрә...
Һәм, мең төскә кереп,
Балкый кояш чишмә суында.
Эх, үбәсе иде шул нурларны,
Эх, аласы иде кулыма!.. –

Һава җитми.
Шау-шу...
Һава җитми!
Йөгерергә иде – хәл беткән.
Тик мин карыйм,
тик мин кайтып киләм,
Һәм әле китмәгән кебек тә...

Фонтан бәрә...
Сәгать суга,
Әмма
Кояш батмый әле – көн үтми.
Шәһәр олы... Тавышымны гына,
Тавышымны гына ишетми...

**ШӘҺӘРДӘ ТӨН**

Шәһәргә төн төшкән, тик якты шәһәрдә.
Ялтырый ай, әмма ул миңа нәрсәгә?
Трамвайлар ашыга тукталыш каршына.
Мин өйгә ашыгам – ник бер сум кесәдә!

Җил исә ыжгырып, умырып изүне,
Әйтерсең яфрак күк очыра үземне.
Мин һава алалмыйм – сүрелә бар җегәр...
Тик өмет күңелдә, тик йөрәк түземле.

Кап-кара ярканат талпына тирәмдә,
Чирәмдә шуыша исерек бер бәндә.
Нур төшми йөзенә. Ул – ялгыз, мин – ялгыз...
Безне кап-карага күмдерә күләгә...

Шәһәрдә инде төн. Тик төне дә якты.
Бер йолдыз атылып йөрәкне канатты.
Сабыр ит, хәзер бу сулагай булган төн
Ыргытыр яктыга мине... Һәм... таң атар.

**ЭЧТӘЛЕК**


Нократ ургып ага... *Г.Морат* .................
**I бүлек**
Каралама .............................
Таң вакыты ............................
«Ял итәргә вакыт...» ......................
Әлхәм ...............................
Казан ................................
Акта кап-кара язулар ......................
Минем дуслар ..........................
«Син беләсең...» .........................
Кече якта .............................
Үтеп барышлый .........................
Башкала ..............................
Җан сагышы ...........................
Көзге моң .............................
Яр Чаллы .............................
Милләт юк ул, диләр ......................
Мин – ярканат ..........................
Башкала. Ак Мәчет .......................
«Дөнья ап-ак...» .........................
Мин – ТАССР улы .......................
Ярым ай ..............................
Халкымның көйләре ......................
«Салкын җир – туң туфрак...» ................
Рамазан ..............................
Яшьтәш ..............................
Татар үлде .............................
Уен .................................

Йөз елдан соң инкыйраз .....................
Бер җыр гына ...........................
Поезд Ижауга бара ........................
Җәй .................................
Гитара уйнады ...........................
Идегәй ...............................
«Ни әйтим...» ...........................
Догаңнан калдырма .......................
Әнкәй, моңаеп карама ......................
«Бер көн үтте...» ..........................
Яра .................................
«Мин яралы...» ..........................
Кая чабасың син... ........................
Мин үземә урын таба алмыйм .................
«Син таш атма башка миңа көлеп...» .............
Эльдорадо .............................
Кайту ...............................
«Күршеләрдә олы бәйрәм бүген...» ..............
Елга буенда тормыш турында уйлану ............
«Йөзәр еллар аша үтеп...» ....................
«Тимә, дәшмә...» .........................
«Ялгыз торганда...» .......................
1552 ел ..............................
«Иртә җиткән, тәрәз шәүләсеннән...» ............
Ул килер .............................
Акрынрак ак, Нократ! ......................
Хуш, Яр Чаллым .........................
**II бүлек**
Беренче мәхәббәт ........................
Син киттең .............................
Ун минутсыз унбер ........................
Атынгыч .............................
Сабый фәрештә .........................
Югалтасым килми минем сине ...............
Мәхәббәт һәм суган .......................
Калмыя буенда ..........................
Мин сине яратам .........................
Сөйгәнемә хат ...........................
«Миләш ачы, диләр...» .....................
«Мин ялгыштыммыни шашып сөеп...» ...........
Гүзәлем ..............................
Башкалада ул ...........................
Җанымның яртысы .......................
Тәүбә ...............................
Оныт ................................
Бию көе ..............................
Караңгы төннәр аша .......................
«Кимсенүне, ачу, әрнү хисен...» ................
Сәлам Рүзәлдән ..........................
«Маңгаемнан сыйпама син...» .................
Сәгать өч инде ...........................
Телисеңме? ............................
«Йолдызлар да юкка чыкты инде...» .............
Саз чәчәге ............................
Кичә ................................
«Минем хыялым булмадың шул син!..» ..........
Син идең .............................
Өч йөз чакрым ...........................
Иске фоторәсем ..........................
«Алай ук җитди карама...» ...................
Син онытма мине .........................
«Әйдә болай...» ..........................
Яңа йөрәк .............................
«Ишетәсеңме, урамда...» ....................
**III бүлек**
Кышкы җыр ...........................
«Урамда бик салкын!..» ....................
«Тын почмакта никтер тынмый йөрәк...» .........
Сагыш ...............................
Буранда ..............................
Гафу ит, әнием ..........................
Тамырлар .............................
Караңгыланды ...........................
Ирекле мин ............................

«Зенит» – «Рубин» ........................
Туган авыл .............................
Чия агачы ..............................
Карлы яңгыр ............................
Яз иде ................................
Хыялым ...............................
Зиратта ...............................
Соңгы юлга ............................
Бу – минем җыр ..........................
«Әкрен генә атлап килә егет...» ................
«Китап, дәфтәр, ачык тәрәз...» .................
«Кабат айлы төн җитте дә...» ..................
Грозный ...............................
Җил умыра читкә мине .....................
«Нинди дөнья...» .........................
«Ярым адым атлап кына...» ...................
«Ярты сәгать...» ..........................
«Ни хәлләрең, туган җирем минем...» ............
«Хуш, Казаным! Синең чикләреңдә...» ...........
«Озатырга чыкма арттан, әнкәй...» ..............
Фонтан ...............................
Шәһәрдә төн ...........................

Литературно-художественное издание

**Мухаметшин** Рузаль Фаизович

**ЧЕРНОВИК**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Мөхәммәтшин** Рүзәл Фәиз улы

**КАРАЛАМА**

Мөхәррире *Ф.И.Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире
*Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 7.05.2010.
Форматы 70r84 $^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 4,36.
Тиражы 1000 д. Заказ О-549.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.